Виниса Фәттахова

Сандугачым, кун учыма

Шигырьләр, хикәяләр, юморескалар

Виниса Фәттахова

Сандугачым, кун учыма

Шигырьләр, хикәяләр, юморескалар

Уфа – 2016

УДК 821. 512. 145
ББК 84 (2 Рос=Тат)-44
Ф 27

Фәттахова В.Ш.
Ф 27 Сандугачым, кун учыма...: Шигырьләр, хикәяләр, юморескалар / Виниса Фәттахова. – Уфа, 2016. – 116 бит.

Популяр җырлар авторы Виниса Фәттахованың дүртенче китабына аның соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләре тупланды. Аларда һәркемнең күңеленә якын булган темалар, тормышта булган гыйбрәтле яки кызыклы хәлләр чагылыш таба.

УДК 821. 512. 145
ББК 84 (2 Рос=Тат)-44

© Фәттахова В. Ш., 2016

ҖИР ШАРЫНЫҢ ОҖМАХЫДЫР...

Җир шарының оҗмахыдыр,
Безнең башкорт илебез.
Йомышыгыз төшмәсә дә,
Күрер өчен килегез.

Зәңгәр күлләргә чумарсыз,
Агыйделдә йөзәрсез.
Җаныгыз шифа тапканын,
Үзегез дә сизәрсез.

Тирә-якны күзәтерсез,
Биек тауларга менеп.
Җырлар җырлап, күңел ачып,
Курай моңына биеп.

Ак каеннар, баллы юкә –
Башкорт иле урманы.
Алмалы, чияле бакча –
Авылларның урамы.

Бетерерлек түгел язып
Мактап башкорт илемне,
Сөеп туялмамын кебек
Шушы гүзәл җиремне.

САНДУГАЧЫМ, КУН УЧЫМА...

Сандугачым, бәләкәчем,
Сайрыйсың да, сайрыйсың.
Минем авыр хәлләремне,
Әллә син дә аңлыйсың?

Таң йолдызы калыкканда,
Сайрарга керешәсең.
Парлы, назлы төннәремне,
Исемә төшерәсең.

Исләремә төшерәсең,
Бәхетле яшьлегемне.
Хәзер килеп беркем какмый,
Көтсәм дә, ишегемне.

Сандугачым, кун учыма,
Икәү бергә сайрашыйк,
Тумыштан минем күңелем,
Синең моңыңа гашыйк.

Телә миңа, сандугачым,
Алда бәхетле көннәр.
Киләчәктә сагышланып
Үтмәсен иде төннәр.

СӨЙГӘННӘР МАТУР БУЛА

Син матурым, гүзәлем син,
Дигән буласың гел дә.
Иң бәхетлеләрдән тоям,
Үземне шушы мәлдә.

Үлеп сөям дигән булып,
Күзең алмыйсың күздән.
Өнемме бу, төшемме, дип,
Сорап куям үземнән.

Чибәрләр чибәр күренми,
Сөйгән чибәр күренә,
Бер күз сирпеп алгач та ул
Менә йөрәк түренә.

Мин дә аны үлеп сөям,
Кыймыйм әйтергә генә.
Кайчан йөзек алмашырбыз
Әйтә алмыйм әлегә.

САЙЛАРГА КИРӘК БЕРНЕ

Чибәрләр күп җир йөзендә –
Сайларга кирәк берне.
Күршемә тарта күңелем,
Әлегә чишмим серне.

Кемнәрнең кем икәнлеген,
Яши-яши аңлыйсың.
Парыңны бер көнгә түгел,
Гомерлеккә сайлыйсың.

Әлегә сынап йөримен,
Күзәтәм читтән генә.
Араларда киртәләр юк,
Бары тик читән генә.

Бер тутырып карау җитте –
Күршемнең күзләренә.
Мәхәббәт хисе түгелә,
Кирәкми сүзләрең дә.

СИН САЙРЫЙСЫҢ...

Язын сандугачлар кайткач,
Яшәрәдер урманнар.
Агачлар да гүя моңга,
Сусап көтеп торганнар.

Күренми дә, үзе сайрый,
Якын каенга кунып.
Ул очып киткәчтен калам,
Күңелем, моңга тулып.

Синең кебек сандугачым,
Мин дә моңлана беләм:
Бары җырлар җырлап кына
Юанамдыр, күңелемнән.

Син сайрыйсыңдыр шатланып,
Кайттым дип, туган җиргә.
Мин сөенәм: имин, күркәм
Яз килә, диеп илгә...

ЯШИК ӘЛЕ СӨЕЛЕП

Картайдым бит инде димә,
Сөеп туймаслык чагың.
Күзләреңдә очкын уйный,
Күзем тимәсен тагын...

Картаерга ашыкма син,
Зинһар, яшьлегеңдә кал,
Күңелемә ялкын салып,
Йөрәгемдә урын ал.

Көннән-көн чибәрләнәсең,
Шулай сыман үземә.
Синнән башка һич берәү дә
Күренми шул күземә.

Иң мөһиме – саф хисләрдер,
Йөрәкләр типсен бергә.
Сөеп, сөелеп яшәргә
Туганбыз бит без җиргә.

МӘХӘББӘТЕМ ТАБЫЛДЫ

Төннәр буе йоклый алмыйм,
Нәрсә булды соң миңа?
Көне-төне уемдасың
Омтыла күңел сиңа.

Очраттым, гашыйк булдым,
Җаныма кунды сагыш.
Югалтулар аша килде,
Кадерледән бу табыш.

Ерактагы кояш җылы,
Диеп юатсалар да,
Яңгырлар явып тормаса,
Чыдам гөлләр дә сула.

Шөкер, килде көткән язым,
Кояшым инде якын,
Көтүем юкка булмаган –
Мәхәббәтемне таптым.

БАРЫ БЕРНИЧӘ АДЫМ

Ак күбәләктәй талпынып,
Янымда әйләндең дә,
Күңелемә килеп кердең
Гомерем җәйләрендә.

Сихерләдең кебек мине,
Бер көн торалмыйм синсез.
Язмышым сиңа бәйләнде,
Синсез мин гүя тиңсез.

Башкаемны әйләндердең,
Үзеңә бәйләндердең,
Ялгыз үткәргән көннәрне
Син гүя ямьләндердең.

Саекмас күңел хәзинәм,
Бул син гомерлек ярым!
Мәхәббәттән бәхеткә бит
Бары берничә адым...

ОФЫКЛАРГА КАРАП

Офыкларга кереп югалганчы
Озатып калдым сине ул чакта.
Һаман да мин кайтуыңны көтәм,
Көннәремне чорнап йомгакка.

Карап торсаң, офык монда гына,
Юлдан язу мөмкин түгел лә.
Сине көтеп шәфәкъ аллана да,
Аннан инде кабат сүрелә.

Офыкларга карап сине көттем,
Каш өстенә куеп кулларым.
Барлый-барлый үткән көннәремне
Еллар сүтә хәзер йомгагым.

УРАП ҮТТЕ АВЫЛНЫ

Күпне күрдең туган авылым,
Гасырлар аша үттең.
Яхшы елда күтәрелдең,
Яман елларда чүктең.

Кояшлы язларны күрдең,
Караңгы көзләрне дә,
Яшенле, кара болытлы
Давыллы көннәрне дә.

Корылыкны да күрдең син,
Уңышлы елларны да.
Синең белән сынау үтте
Кызларың, улларың да.

Барысына да шаһит син:
Кем килгән, кемнәр киткән.
Кемнәреңнеңдер исеме
Тарихка күчкән икән.

Берни читләтеп узмады,
Бары сиңа кагылды.
Шәһәр – герой, бу исем ник
Урап үтте авылны?

Тарихтан килгән аваз бу
Тәкъдир итә, заманым!
Мин, авылым, сине данлап
Бары җырлар язамын.

ВАКЫТ ТА ТӨЗӘТӘЛМИДЕР

Яшьлек йөгереп үтәр дип,
Уйламадым һич кенә.
Бирешүен бирешмим дә
Бетеп бара көч кенә.

Инде йөгерермен димә,
Бик тиз тала аяклар.
Таяныр да идем инде –
Ярдәм итми таяклар.

Юкка гына әйтмиләрдер,
«Картлык шатлык түгел», дип.
Яшь үстерү җиңел лә ул,
Яшәү рәхәт түгел бик.

Баштан ни генә кичмәде,
Тормыш бик тә катлаулы,
Таләп итә тырышлыкны,
Хупламый тик ятканны.

Ачлыкта, ялангачлыкта
Түздек, кая барасың,
Вакыт та төзәтәлмидер
Кайбер күңел ярасын.

Рәхмәт әйтәм Ходаема,
Әлдә исән-иминмен.
Биргәненә шөкер итәм,
Булмаганга көенмим.

ТУЕГЫЗ БЕЛӘН...

Мәхәббәт килә бер тапкыр
Һәм яши гомер буе.
Саф күңелдән сөйгәннәрнең
Бер генә була туе.

Арагызда сөю хисе
Беркайчан сүрелмәсен.
Ят чәчкәгә күңелегез
Беркайчан үрелмәсен.

Агачында торса гына
Кызарып пешә миләш.
Арагызда булсын һәрчак
Уртак уй, уртак киңәш.

Яшәгез гел рәхәт күреп,
Туган көнгә сөенеп.
Кайгы сезне урап үтсен,
Шатлык торсын өелеп.

Сабыр итә белү кирәк
Нәфрәтегез ташса да,
Мәшәкатьләрегез артып
Башыгыздан ашса да.

Яшәгез бәхетле, озак,
Таза, исән-сау булып.
Өй эчегез гөрләп торсын
Бала-чагага тулып.

ОНЫТЫЛМЫЙ ҮТКӘННӘР

Гомер көзенә җитсәм дә,
Күңелдә чәчәкле яз.
Шөкер итәм Ходаема,
Көнем күркәм һәм аяз.

Тагын кайттым әле менә
Сабан туен күрергә,
Авылдашлар, сезнең белән
Күңел ачып йөрергә.

Оныткандыр бу, димәгез,
Онытылмый үткәннәр.
Шул үткәннәремә бәйле
Исәннәр һәм киткәннәр.

Яшь арткан саен көчәя
Сезне сагынуларым.
Күрешеп бер сөйләшүдер –
Сагынуга даруларым.

Колач җәеп каршы ала
Һәрбер йорт һәм һәр капка.
Мактанам, кунакчыл халык
Яши дип, безнең якта.

Исән булыйк, тату яшик,
Ил-көн кайгы күрмәсен.
Авылыбыз исемен данлап
Сабантуйлар гөрләсен.

БЕР ГЕНӘ...

Бер генә, бары бер генә
Бирелә гомер безгә.
Тоеп туймый җәй ләззәтен
Керәбез аннан көзгә.

Эх, гомер ике килсә, дип,
Уфтанабыз кайчагын.
Әгәр чынлап шулай булса
Ни эшләр идек тагын?

Аптырыйбыз, күзаллау да
Фараз гына нибары.
Ни эшләреңне белмәгәч
Ник сорыйбыз соң аны?

Минемчә, бер гомер җитә
Яшәсәң яши белеп,
Озак яшәүдән ни мәгънә,
Асылың булса черек.

Гомер икенчегә килсә
Кадерен җуяр төсле,
Һәр мизгел бит безнең үзгә,
Кичерешле һәм хисле.

Гомеребез мизгелләре
Кабатланмаган кебек,
Ике килми гомерләр дә
Яшик кадерен белеп.

ТУГАН КӨНГӘ...

Яшьлек язын үткәрдең дә,
Җәй мизгеленә кердең.
Картаямын, дип, уфтанма,
Тулды бит бары иллең.

Чыраең яшь, буй-сының төз,
Элеккечә матурсың.
Гомер көзеңә дә шулай
Үзгәрми керү язсын.

Кайгы күрми генә яшә,
Сөйгәнең белән бергә.
Төшенкелеккә бирелми
Үрлә әйдә, гел үргә!

ЯШƏ ƏЛЕ...

Төшермə əле күңелеңне,
Картайдым инде, диеп.
Тормыш юлын матур үттең,
Яшəмəдең син көеп.

Уңышларга да ирештең,
Тырыштың гомер буе.
Җырлап-биеп кенə үтсен,
Түгəрəк гомер туең.

Исəн-сау бул, гел шат яшə,
Рəхмəт əйтеп Ходайга.
Тормышың бик җиңел барды,
Искəндер җил уңайга.

Күңелеңне били синең
Изгелек хисе генə.
Шуңа да рəхмəтлəр генə
Явадыр исемеңə.

Яшə əле озын-озак,
Сөенеп, сөендереп.
Утыртырлар үзеңне дə
Түр башына мендереп.

ТУЙМАДЫҢМЫ, ДӨНЬЯЛЫК?..

Чуар күңелле бәндәләр
Туалар да дөньяга,
Эч керләрен тотыналар
Анда-монда ягарга.

Мәкер аларга – әйдәүче,
Юлдашлары – ялгандыр,
Ни үкенеч, бер сафларда
Атлау безгә язгандыр

Хәнҗәрдәй сүзне кадарга
Һәрвакыт әзер алар.
Алдагыларга, көнләшеп,
Һәрчак аяк чалалар.

Еллар авыр, болгавыр дип,
Әрлибез без заманны.
Әнә шул чуар күңелләр
Болгаталар бит аны.

Акны карага манчыйдыр
«Һә» дигәнче бу халык.
Мондый күз бууучылардан
Туймадыңмы, дөньялык?

ӨЗЕЛДЕ ГОМЕРЛӘРЕ

Күпләр каршы алалмады
Шатлыклы җиңү көнен,
Тик газиз әнкәйләр генә
Көттеләр көнен, төнен.

Пәһлевандай япь-яшь ирләр
Әйләнеп кайталмады.
Туган йорт көтте аларны,
Япмыйча капкаларын.

Кайларда ятып калдыгыз
Уллары туган җирнең?
Бүген менә чәчәк тотып
Һәйкәлегезгә килдем.

Сезнең исемнәр мәрмәргә
Алтын белән язылган,
Яныгызга инде хәзер
Такыр сукмак салынган.

Картәтәй, картинәй булды
Күптән ул-кызларыгыз.
Хәлегезне белергә дип,
Килә оныкларыгыз.

Әткәмне искә төшерәм
Карыймын да һәйкәлгә,
– Сөен, әткәй, искә алыр
Кызың бар димен, әлдә!

Күпме үсмер, яланында
Сугышның калды ятып.
Алар яшәүнең тәмен дә
Өлгермәде бит татып.

Ташка уелган исемнәр
Кисәтә кебек барсын:
– Уяу булыгыз, оланнар,
Гарасат уянмасын!

КАДЕРЕН БЕЛ

Гомер буе йөрәгемдә
Илешем – туган ягым.
Синең җылы кочагыңда
Үтте бит бала чагым.

Балачак хатирәләре
Онытылмый беркайчан,
Уем белән мин еш кына
Хәтер сандыгын ачам.

Күкрәк киереп сулыйм һәрчак,
Саф һавасын урманның,
Эзләп йөримен эзләрен
Үлән баскан юлларның.

Күтәрелеп тау башына,
Күз салам тирә-якка.
Җәелеп ята авылым,
Күренә безнең капка.

Авылым күркәмдер һәрчак,
Тумасын кайсы мизгел,
Өндидер кебек: соклан да,
Гүзәллек кадерен бел!

СИН БУЛМАСАҢ ЯНЫМДА

Син – минем бәхет йолдызым,
Балкыйсың төннәремдә.
Сиңа гына багышлана
Җырымның сүзләре дә.

Синнән башка берәүне дә
Күрергә дә теләмим.
Кайнар мәхәббәт сүзләрен
Беркемгә дә сөйләмим.

Кояшлы көн гүя томан,
Син булмасаң янымда.
Бәгырькәем һич җәл түгел,
Синең өчен җаным да.

Көтеп торсын безне һәрчак
Алда үтәсе юллар,
Шатлык, бәхет бүләк итсен
Безнең киләсе еллар.

БӘГЫРЬНЕ ӨЗӘР МИКӘН

Дару да юк, им-том да юк
Сөю дигән газапка.
Кемнәрдер аңа соклана,
Кемнәрдер гайбәт сата.

Өннәремдә күрәлмәсәм
Төшкә керәсең, ярый.
Сине уйлап йөри-йөри
Булам инде хыялый.

Күзләремә кара әле,
Бәлки, аңларсың иркәм,
Сөю, наз тулы карашны
Нигә күрмисең икән?

Гашыйк булдым, янам эчтән,
Йөрәгем түзәр микән?
Җавапсыз мәхәббәт булып
Бәгырьне өзәр микән?

КАРАМЫЙЧА БЕЛӘККӘ

Кемдә бәхет – бер олы күл,
Кемдә кечкенә елга.
Төрлечә бара шул тормыш,
Ел туры килми елга.

Язмышы да әллә нинди,
Туры килми теләккә.
Тәкъдир кыенлыклар сала
Карамыйча беләккә.

Күгем аяз, юлым якты,
Бәхет көтәдер алда.
Авыр чакта таянырга
Булсын сөйгәнем янда.

Сыңар уч бәхетемне дә,
Кабул итәм куш итеп.
Көзен килгән бәхеткәем,
Югалма, кышын китеп.

ЯНМЫЙЧА ТҮЗЕП КАРА

Сандугачлар өзелеп сайрый
Таң атканда, тирәктә.
Йолдыз сүнәр, син балкырсың
Йолдыз кебек, йөрәктә.

Таң йолдызы җем-җем итә
Сүнәсе килми микән?
Минем өзелеп көтүемне
Әллә соң белми микән?

Йолдызның сүнәсе килми
Минем йөрәк тә яна,
Таштан яралмаган бит ул,
Сагышка түзеп кара...

ТҮЗӘМ ИНДЕ БЕРАЗГА

Сусагандыр җаның назга,
Бәлки, кайтырсың язга?
Кайтам дигәч, бер кайтырсың,
Түзәм инде беразга.

Күптән көткән асыл кошым,
Очып кайт яннарыма.
Күк күгәрчен кебек гөрләп,
Килеп бас алларыма.

Һәркемнең теләдер җанын
Аерылышу газабы.
Аерылуга түзәр идем,
Кавышалсак азагын.

Очып төштең яннарыма,
Әлләме зәңгәр күктән?
Кайларда йөрдең адашып,
Мин сине көтәм күптән.

ОНЫТМАДЫК

Бүген синең туган көнең,
Без онытмадык аны.
«Ничә яшь?» – дип сорамыйбыз,
Мөһим дә түгел саны.

Көне дә көлеп уянды:
Кояш нурларын сибә.
Күзләреңнең шатлык яше
Керфекләреңдә кибә.

Гел елмаеп, көлеп яшә,
Гомерең озын булыр.
Хәрәкәттә – бәрәкәт, ди,
Яшең йөзгә дә тулыр.

Бәхет, озын гомер теләп,
Җан җылысын бирәбез.
Аллаһ бирсә, исән булсак,
Яреңгә дә киләбез!

КАРШЫЛЫЙК БЕРГӘ

Бер сандугач килеп кунды
Язын тал-тирәгемә.
Сөю дулкыны кагылды,
Наз көткән йөрәгемә.

Сайрыйсым килә шатлыктан,
Кушылып сандугачка.
Колакта – сандугач моңы,
Уянам таң тугач та.

Йөгереп чыктым бакчага,
Сайрар кошны күрергә.
Сайрар кош – сөйгәнем икән,
Кыймый өйгә керергә.

«Миндә дә гыйшкый халәт, – ди, –
Мин дә, – ди, – сине сөям. –
Син генә, иркәм, бирәсең
Күңелемә сихри ямь.

Моңга күмелгән таңнарны
Каршылыйк, әйдә, бергә.
Адәм белән Һава да бит
Парлап яшәгән җирдә».

ОЧРАДЫ ЮЛЫМДА

Йөрәк – ул серле бер йозак,
Ярамый төрле ачкыч.
Йөрәк түре биек җирдә,
Юктыр менәрлек баскыч.

Ачкыч була бирәү генә,
Тик берәүнең кулында,
Ачкычлы бер изге күңел
Очрады ла юлымда.

Килеп керде дә йөрәккә,
Уйламый да чыгарга.
Минем кебек көйсез затка
Җыенамы чыгарга?

Җыенмаса ачмас иде,
Кермәс иде күңелгә.
Әллә икебез бер төсле,
Телләшкән юк әлегә.

ҖАН ДУСТЫМА

Ахирәтем – җан дускаем
Кадерле син миңа бик.
Дус булырбыз гомер буе,
Язмыш аермасын тик.

Дуслар тапсаң, сына башта,
Сыналганы – тугры дус.
Булыр-булмас кешеләрне
Ерактан ук урап уз.

Иске дустым – сыналган дус,
Туганым кебек якын.
Пакь күңелле, эчкерсез зат
Тора ай кебек балкып.

Ярдәм кирәк була калса,
Килеп җитә йөгереп.
Исәнлек-саулык сораша
Минем хәлемә кереп.

ЯЛГЫЗ ХАТЫН

Ялгыз хатын күтәрәдер
Авыр йөк тә, авыр сүз дә,
Ул тегеләй, ул болай, дип,
Чәйнәгәннәргә дә түзә.

«Синең эшең бармы, – диләр, –
Елап утырмый балаң.
Эчә торган ирең дә юк,
Чәйнәнә торган кайнаң».

Менә шулай уйлыйлар да
Тиңлиләр ваемсызга,
Ялгызларның күңелләрен
Рәнҗетеп урынсызга.

Җан биргәнгә юнь бирер, дип,
Әйтеләдер электән.
Шул юненә таяна ул,
Ялгыз хатын күнеккән.

КҮК КАПУСЫ

«Иртән бәхет өләшәләр, –
Дия иде нәнәем. –
Таңнан торып бәхет телә,
Йоклап ятма, бәбәем!

Елына бер тапкыр гына
Күк капусы ачыла.
Тирә-якка нурын сибеп
Аннан бәхет саркыла».

Таң чыкларын яра-яра,
Йөгерәм ялан иңләп,
Күк капусы ачылганын
Күрәсем килә тизрәк.

Иртән бәхет өләшәләр,
Йоклап ятмагыз озак.
Бәхет таба алмасагыз
Үкенерсез бит азак.

КИЛ ЯНЫНА БИЧАРАНЫҢ

Беркемгә дә кирәге юк –
Берәү ята урамда.
Җәнлек килеп иснәр иде
Әгәр ятса урманда.

Исерек, диеп көләләр,
Якын килми бер кеше.
Урап узалар йөз чытып,
Һичберкемнең юк эше.

Егылгандыр, бәлки, бәндә,
Йөрәге-фәлән тотып?
Якыннары югалткандыр,
Торалардыр ут йотып...

Кил янына бичараның,
Битараф калма, зинһар,
Иртәгәсен шул урында
Үзеңнең ятуың бар!

СӨЕКЛЕ КЫЗЫКАЕМ

Кызыкаем – йөрәк парәм,
Шатлыгым, куанычым.
Син – күңелем чәчәгедер,
Син – гомер юанычым.

Сау-сәламәт булып яшә,
Кадерле балакаем.
Сөекле кызыкаема,
Бәхет бир, Аллакаем.

Акыллы, зирәк булып үс,
Ак җәймә юлларыңа,
Бәхетең, күңел чәчәгем
Үзеңнең кулларыңда.

Тормышка ашсын хыялың,
Офыгың аяз булсын,
Фатихамны бирәм сиңа,
Юлларың һәрчак уңсын!

ҮЗӘКЛӘРЕМ ӨЗЕЛӘ

Һич уңалмыйдыр бу яра
Айлар, еллар үтсә дә.
Һаман сине юксынамын
Инде күптән китсәң дә.

Инде онытылыйм дисәм,
Төшләргә керәсең шул.
Хәл белергә кайт дисеңдер,
Җыенган булам ла ул.

Җыенуын җыенам ла,
Тазалык шул чамалы.
Шуа түбән, тыялмыйсың
«Гомер» дигән чананы...

Ниһаять, янә күрештек,
Ходаем насыйп итте.
Тамакны ачыткан төер
Гүя чишелеп китте...

Үзем чәчәкләр утыртам,
Күз яшьләрем – сугара,
Бу югалтуның ачысын
Мөмкин түгел җуярга.

Әнкәй, газизем, ятасың,
Инде җир кочагында,

Баш очында лепердиләр
Каеннар уйчан гына.

Нәрсә хакында лепердәп
Серләшәсез яфраклар?
Килү бар, дисез, шикелле,
Дөньялыктан киту бар.

Инандым, ошбу хакыйкать
Кагылгачтын үземә,
Әнкәйләр мәңгелек түгел,
Үзәкләрем өзелә...

ГАРМУН МОҢЫ

Элек-электән үк бездә
Гармунчылар иң түрдә,
Бәйрәмнәрдә, табыннарда
Гармун күңелне күрә.

Эх, димен, шулай сыздырып
Гармун уйнасаң иде.
Моңга күмеп айлы кичне
Урам буйласаң иде.

Кызлар кушылырлар иде
Мин уйлаган көйләргә,
Үтеп керер иде моңым
Урамнардан өйләргә.

Ходай бирмәгән шул никтер,
Андый сәләтне миңа.
Моңга кушып сәламемне
Җибәрер идем сиңа.

Әлегә гармунчы белән
Янәшә генә атлыйм,
Тиздән, (тик сер итеп әйтәм),
Үзем дә уйный башлыйм.

СОҢ БУЛСА ДА

Соң булса да очраштык,
Бәлки, соң да түгелдер.
Син – болытлардан арчылган
Минем аяз күгемдер.

Күптән сүнгән учак уты
Шөкер, тагын кабынды.
Яшь чакта ник аерылыштык,
Кайсыбыз соң абынды?

Син бер көлсәң – кояш чыга,
Елмаясың – ай калка.
Үзең янымда чакта да
Уйлыйм гел синең хакта.

Саф мәхәббәт яши икән,
Айлар, еллар үтсә дә.
Сөю хисе сүнми икән,
Учакта ут сүнсә дә...

ЯЗЛАР КИЛӘ

Әкрен искән йомшак җилләр
Яз килүен белгертә,
Ак каеннар бөреләрдән
Яшел яфрак өлгертә.

Куандырып күңелләрне,
Язгы су килә гөрләп.
Җылы кояшка назланып,
Үрмә гөл китте үрләп.

Язгы һава – җанга дәва,
Шифадыр ул күңелгә.
Әйтерсең, өрә сулышын
Күңелдә үсәр гөлгә.

Бөтен тереклек уяна,
Үләннәр чыга калкып.
Чәчәкләр ачалар таҗын,
Җир йөзе тора балкып.

Язлар – гүя бер могҗиза,
Сокланып карыйм һәрчак,
Камил булыр иде дөнья
Без дә яшь көе калсак.

Яшел торса гелән дөнья,
Агачлар чәчәк атса,
И шушы күркәм тормышта
Яшьлек тә кире кайтса!

ИҢ КУЛАЙ КЕШЕ

Баеп булмый, дускайларым,
Тир түгеп эшләп кенә.
Дөньясы да аяп тормый,
Кимсетеп синнән көлә.

Бай туган кирәк кемгә дә,
Хәерче – беркемгә дә,
Кунак булып баралмыйсың
Син аңа беркөнгә дә.

Кесә төбе тишек булып
Җилләр уйнап торганда,
Син бар ни дә, юк ни аңа,
Бу һавалы дөньяга.

Авырый калсаң әгәр дә
Таянырсың кемнәргә?
Баралмыйсың имчегә дә,
Акча кирәк имгә дә.

Әмма эшкә кирәк булса,
Чакыралар беренче.
Аттай җигелеп тартырга –
Ярлы – иң кулай кеше.

АРАЛАП КЫНА КИЛӘ

Бәхет елмаймый һәркемгә,
Аралап кына килә.
Кемгә бәхетне бирергә
Ходай, күрәсең, белә.

Мәхәббәт бәхетен Ходай
Миңа да бирде бүлеп.
Яшь йөрәгемне җилкетеп
«Яратам, – диде, – үлеп!»

Ышандым, ышанмадым да,
Төш күрәм, дип уйладым.
Күңелемнән аның белән
Гомер юлын буйладым.

Язмышмы шулай шаярды,
Ялгышыммы ияртте,
Мине аңардан аеру
Кемнәргә соң кирәкте?

Юаткан була кайсысы:
– Бәхетең алда әле,
Сабыр ит, сөю кошының
Тик канат ярган мәле...

Көткәннәр көтсен, мин генә
Түзеп торалмам сыман.
Син – бәхетемне – эзләргә,
Юлларга үзем чыгам.

ӘБЕКӘЙ ДИСӘГЕЗ ДӘ

Артта калганнардан түгел,
Әле бик чапмасак та.
Акылсыз да түгел болай,
Бик акыл сатмасак та.

Ким-хур булып яшәмәдек,
Чибәр үк булмасак та.
Чибәрләр үзе иярде,
Без булдык алгы сафта.

Яшьлектә без җиң сызганып
Юл башладык һәр эштә.
Ил чакыргач киттек бердәм
«БАМ» дигән төзелешкә.

Әл(е)дә әле күңелебез
Уналты, унсигездә.
Җиң сызганырга әзер без,
«Әбекәй», дисәгез дә.

ТЕЛИСЕҢДЕР КҮРЕРГӘ

Төшләремә гел керәсең,
Онытмасын дисеңме?
Әле булса җырларыма
Кушам синең исемне.

Сагышлардан өзгәләнеп,
Үлсәм йөрәгем янып,
Ниләр эшләрсең дөньяда,
Минсез, берүзең калып.

Күзләрем талганчы карыйм
Агыйдел агышына.
Йөрәгем ничек түзәдер
Аерылу сагышына.

Төшләремә керә-керә
Ни уйлап йөрисеңдер,
Назга сусаган йөрәкнең
Хәлләрен белмисеңдер.

ҮЗЕ ИҖАТ ИТӘДЕР

Сокланып туялмам кебек
Шушы матур дөньяга.
Тотып туктатып булмый тик
Гомер ага да ага.

Әле бары тик туплана
Язасы фикерләрем.
Күңелемнең төпкелендә
Ачылмаган серләрем.

Ходаем, суз озаккарак
Гомер дигән фасылны,
Чуалтмыйча торсаң иде
Уй-зиһенне, акылны.

Бәлки, әле уңышлар да
Киләчәктә көтәдер.
Мин каләм тибрәтәм – тормыш
Үзе иҗат итәдер.

СӨЮ УТЫНДА ЯНА

Кар бөртекләре уйныйлар,
Ай йөзә якты күктә.
Сөеклем дә килеп җитте
Вакыт үтмәде күп тә.

Кочып алды мине иркәм,
Бөтерелде, әйләнде.
Мин дә аңа сарылдым да
Чәчләр чәчкә бәйләнде.

Кар бөртекләре уйныйлар,
Ай якты нурын сибә.
Йөрәктә мәхәббәт хисе –
Сөям-сөям дип тибә.

Мәхәббәт ул – олы бәхет,
Тик тәтеми барсына.
Көтмәгәндә килеп чыга
Колач җәеп каршыңа.

СУГЫШ ЯРАСЫ

Иң авыры бу дөньяда –
Якыныңны югалту.
Сөйләп кенә булмый моны,
Мөмкин түгел аңлату.

Җәйләр үтә, кыр казлары
Очып китә күлләрдән.
Йөрәк сызлый, күңел елый,
Яшь түгелә күзләрдән.

Язлар килгәч кошлар кайтыр,
Тик син генә кайтмассың,
Елмаеп ишекне ачып,
Күз алдыма басмассың.

Йөрәгемнең иң түренә
Бу – сугыш салган яра.
Истәлекләр белән генә,
Әткәй, күңлем юана.

ЯШӘГЕЗ СӨЕП-СӨЕЛЕП

Ни әйтсәң дә, сикәлтәсез
Булмый шул гомер юлы.
Чокыр-сикәлтәсе белән
Тормыш һәрвакыт тулы.

Сабыр гына үткәрә бел
Һәр четерекле хәлне.
Авыр чакта хәтерләгез
Сөю кабынган мәлне.

Үрмә гөлләр булып сарыл
Иркәңнең муенына.
Кочып ал да кереп сыен
Син җылы куенына.

Шулай үтсен һәр көнегез,
Зур бәхеткә сөенеп.
Бер-береңне аңлый белсәң,
Яшәмәссең көенеп.

АБЫЕМА

Әл(е)дә син бар, абый җаным,
Туганым, канкардәшем.
Ялгыз түгелмен дөньяда,
Бар туганым, сердәшем.

Әл(е) дә син бар әле, диеп,
Сөенәм, абый җаным.
Таянычым бар дөньяда,
Шунысы мөһим бит аның.

Акыллысың да, уңгансың,
Һәрьяклап миңа үрнәк.
Ачык йөзле, киң күңелле,
Итәм шуңа да хөрмәт.

Төшеп калганнардан түгел,
Китмәсәң дә бик үрләп.
Картлыкка да бирешмисең,
Яшисең, шөкер, гөрләп.

СОКЛАНЫПЛАР ТУЯ АЛМЫЙМ

Җил сызгыра, буран дулый,
Көрт ята урамнарга.
Сөйгән ярым килмәс инде,
Кем йөрсен бураннарда.

Күңелем барыбер көтә,
Тәрәз(ә)дә ике күзем.
Саг(ы)нуымның чамасы юк
Әллә барыйммы үзем?

Ап-ак буранга уранган
Иркәм атлый урамнан.
Ул да миңа каршы килә
Курыкмаган бураннан.

Киртә түгел гашыйкларга
Көрте дә, бураны да.
Сокланыплар туя алмыйм
Буранлы урамыма.

ӘЙЛӘНДЕРМӘ БАШЫМНЫ

Чәчәк атмаган гөлләрне
Утыртма син бакчага,
Сөям, диеп ышандырма,
Күңелең булгач башкада.

Яратмагач – араны өз,
Әйләндермә башымны.
Очратырмын сөя белгән
Мин дә йөзек кашымны.

ЯЛЫНДЫРГАН БУЛАСЫҢ

Гел ялындырган буласың,
Борының чөеп күккә.
Дөрләп янган гыйшык уты
Бармас ул, иркәм, күпкә.

Бер дә су күтәрми серкәң,
Үпкәлисең юкка да.
Ачуланып, китәм диеп,
Тотынасың тоткага.

Шаярып әйткән сүзгә дә
Кашың җимерелмәсен.
Мәхәббәт кич кабынса да,
Сүнмәс, димә, иртәсен.

Масаеп йөргән кызларны
Өнәмәдем элек тә.
Үзеңне бик зурга куйсаң,
Карамам бер килеп тә.

КАРТӘТИЕМ

Исемә төшә дә тора
Бәхетле балачагым.
Кайтыр идем кайтып булса
Әйләнеп шунда тагын.

Тартадыр, тарта үзенә
Картәтием нигезе.
Җимешләр тулы бакчаның
Уңышлы алтын көзе.

Балачак хатирәсеннән
Килә кадерле кешем.
Картәтиемә бәйледер
Бүген дә күргән төшем.

Кармак салганбыз да, имеш,
Яр башына утырып,
Тоттык хәтсез генә балык
Чиләгебез тутырып.

Балык ул байлыкка, диеп,
Юрыйлар безнең якта,
Байлыгым – хатирәләрем,
Юанычым бу чакта.

Төшләрем бала чагымнан
Якты истәлек кенә,
Язылачак җырларыма
Күркәм эчтәлек менә.

АЛЫШТЫРМЫЙМ АКЧАГА

Минем йортым бакчада,
Тирә-ягы чәчкәдә.
Су сибәмен, түтәл утыйм,
Эшем бетми кичкә дә.

Шушы гүзәллеккә карап,
Сокланам үзем һәрчак.
«Әлдә әле бакчам бар», – дип,
Сөенәмен дә кайчак.

«Нәрсәгә сиңа ул бакча,
Өлкәнсең, ташла, – диләр.
Кулыңнан килердәй җиңел
Юкмы эш башка?» – диләр.

Кара җимешле миләшем,
Кып-кызыл баланнарым,
Алланып пешкән агачта
Йөзләгән алмаларым.

Хозурланып чыгып басам
Шушы ямьле бакчага.
Ничек аны кызганмыйча
Алыштырыйм акчага?

КИРӘК СӨЙГӘН ЙӨРӘК

Булмый икән шул яратып
Ятмаса күңеленә,
Чагыштырып йолдыз белән,
Тиңләп бакча гөленә.

Яратуыңны беләмен,
Сөясең мине чынлап.
Тик иркәм, кара әле син
Минем йөрәкне тыңлап.

Ул тибә, гадәттәгечә,
Әкрен, салмак кына.
Талпынмый да, җилкенми дә,
Үзен бик санлап кына.

Сөйгән йөрәк ул – тынычсыз,
Дөпелдәп тибә, шаша,
Әйтерсең лә, тойгылары
Күкрәккә сыймый таша.

Сиңа мин түгел, ә шашкан
Йөрәк иясе кирәк,
Шашу – сөю билгесе ул,
Сөйгәнне тап тизрәк!

ЯҢА ЕЛГА

Көтеп алган Яңа елым
Ниһаять, килеп җитте.
Шатлыгы, кайгысы белән
Иске ел узып китте.

Яңа ел нәрсә китерер
Аны соң кемнәр белә?
Аяк баскач яңа елга
Ходайдан бәхет телә.

Өмет итәбез уңышлар
Яңа киләсе елдан.
Адәм баласы, ялгышып,
Чыкмасын тугры юлдан.

Илебез тыныч яшәсен,
Килмәсен бәла-каза.
Авырлыкларны җиңәрбез
Булсын рухыбыз таза.

Атлап керсен Кыш бабабыз
Җиңел аягы белән.
Ирештерсен теләкләргә
Тылсым таягы белән.

БЕЗНЕҢ КАЛА

Үскәннән үсәдер бүген
Безнең Уфа калабыз,
Төзү эше кайнап тора,
Көн дә бер йорт салабыз.

Кичәге бушлыкта бүген
Инде бина калыккан.
Калабызның төзеклеге
Тора эшче халыктан.

Хезмәткә карап хөрмәте –
Матур кала бүләккә.
Фатир көткәннәрнең саны
Кимиячәк, әлбәттә.

САГЫНЫП СӨЙЛӘРГӘ КАЛСЫН

Уртак уйлар, уртак максат
Тормыш шуннан башлана.
Шушы гүзәл парны, Ходай
Рәмәтеңнән ташлама.

Мин дә сезгә чын күңелдән
Телим бәхет, уңышлар.
Бәхетле куышыгызны
Җимермәсен ялгышлар.

Тәгәрәп үссен балалар,
Идән тулып, өй тулып.
Үссеннәр имәндәй таза,
Акыллы, батыр булып.

Мәхәббәт, үзара хөрмәт –
Матур гаилә нигезе.
Тату гаиләләргә тия
Гомерләрнең тигезе.

Йөрәгегез берсен-берсе
Аңлап яшәргә язсын.
Бергә үткән елларыгыз
Сагынып сөйләргә калсын.

КАДЕРЛЕ КЕШЕМ

Шәфкать тулы күңелкәең
Сүрелмәсен, сүнмәсен.
Шатлыкта үтсен гомерең,
Кайгы-хәсрәт күрмә син.

«Чәчләрем дә инде ап-ак», –
Диеп борчыласың син.
Йөгереп йөргән яшьләрдән
Кай ягың белән син ким?

Ашыкма гомер көзенең
Тәкъдирдә язганына,
Көзләр килеп китә торсын,
Ә син кал язларыңда!

Яшә әле озын-озак,
Күңелең назга тулып.
Авыр чакта сөялергә
Безнең таяныч булып.

Кайтып керсәң, ишек ачык,
Шул мөһим минем өчен.
Колачың киң, йөзең ачык
Апам – кадерле кешем.

САЛКЫН КӨЗДӘ ӘНИ ТУГАН

Салкын көздә әни туган,
Балан өлгергән мәлдә.
Язмышы да шуның өчен
Ачы булганмы әллә?

Әткәемне кайтыр диеп,
Сугыштан соң да көткән.
Тәкъдирен пары иткән ул,
Гомере ялгыз үткән.

Ачы язмыш сагышлары
Телгәләгәндер аны,
Кая куярга белмәгән
Чагы булгандыр җанын.

Йокысыз үткән төннәрнең
Юк исәбе, юк хакы.
Күпме еллар ялгыз яшәп
Чыкмады яман аты.

Бердәнбер кызы – җимеше
Гомерлек куанычы.
Үткән тормыш юлларында
Булдым мин юанычы.

ТУГАН КӨНДӘ

Туган көнгә килде Закир,
Җан дусты Замирларга.
Ару гына салып алгач
Тотындылар җырларга.

Шешә артыннан шешәләр
Бушады бер-бер артлы.
Янып-пешеп эчә торгач,
Көч тә, гайрәт тә артты.

Закир күз сала башлагач
Дустының бичәсенә,
Хәлләр кыркулана төште
Туган көн кичәсендә.

Юк, кичерә алмый Закир
Бу мәкер-хыянәтне,
Күрсәтмәкче ул боларга
Җирдәге кыямәтне.

Өйдә дөмбәсләшеп алгач,
Чыга болар урамга.
Күрше карчыкның киртәсе
Әйләнәдер коралга.

Бичә дә читтә калмыйдыр,
Килеп керә сугышка.
Бу икәүне чәмләндереп
Киртә ташый, «булыша».

Уянгач болар махмырдан,
Карасалар иртәсен...
Сүтеп-сындырып беткәннәр
Күрше карчык киртәсен..

КАРТ БУЙДАКЛАР

Карт буйдаклар дисәгез дә,
Ташып тора дәрт-дәрман.
Егетләр булып калабыз,
Уйда тик кызлар һаман.

Дөнья көткән кеше эчми,
Ә сез эчәсез, дисез,
Бөтенләй капмаган ирләр
Булалар алар көйсез.

Без төшерсәк төшерәбез
Чамасын белеп кенә.
Кызлар белән сөйләшәбез
Елмаеп-көлеп кенә.

Юлдан язмаганбыз әле,
Каермыйбыз без сулга.
Кирәк булса, кер юабыз,
Барабыз хәтта суга.

Үкенмәссез кызлар, бездәй
Егетләр ятмый аунап.
Карт кыз булып калуыгыз
Бар бит, безне яманлап...

ИСКӘ ТӨШӘ

Төшләремдә балачакка
Еш кына кабат кайтам.
Иркәләнеп таң чыгында
Хәтфә чирәмдә ятам.

Күзәтәм бар табигатьне,
Могҗиза – тирә-ягым.
Кайларда калдың адашып,
И гүзәл бала чагым?

Искә төшә әнкәемнең
Иркәләп сөюләре.
«Син бит – минем бердәнберем,
Бәхетем», – диюләре.

Ярый әле төшләремә
Кереп торасың гел дә.
Балачак, китмәдем читкә
Яшимен синең илдә.

ЧАНА ШУГАНДА

Яратам кышкы буранны,
Ике күзем урамда.
Карасам, кем килә, диеп,
Барый атлый буранда.

Ява, оча, бөтерелә
Мамык кар бөртекләре.
Атлый Барый бата-чума
Ак киез итекләре.

Күңеле шат, авыз ерык,
Күреп торам ерактан.
Ап-ак бүрек, ап-ак пальто –
Киеме бар да актан.

Бар киеме, дисәм, актан,
Ул икән карга баткан.
Кайтып килә таудан шуып,
Олы чанасын тарткан.

Әтием дә ясап бирде
Миңа да шундый чана.
Шуабыз таудан тәялеп,
Тирә-як бала-чага.

Үзем чакырдым Барыйны –
Күмәк уйнау күңелле.
Таудан төшәбез тәялеп,
Узабыз хәтта җилне.

БЕЛГЕЧ ТУМАГАН ӘЛЕ

Йөрәгемә килеп кердең,
Ишекне шәрран ачып.
Түремә үк үтеп киттең,
Бик кыю гына басып.

Ут кабыздың йөрәгемә,
Ул хәзер дөрләп яна,
Кара күмергә калганчы
Кичектерми күр чара.

Табибка күрен, дисеңме,
Ирешенәсең, әйеме?
Мәхәббәт утын сүндерер
Белгеч тумаган әле.

Битараф булып күреним,
Бер булсын егет сүзе,
Әгәр дә ярата икән.
Йөгереп килер үзе.

Чынлап та йөгереп килде,
Суытмый арабызны.
– Йөрәгеңне дәвалыйк, – ди,
Кинога барабызмы?

САГЫНУ

Авылымны сагынуым
Бәгырьләремә үтә,
Әйтерсең лә мине анда
Һаман әнкәем көтә.

Хуш исле икмәген салган,
Чүлмәктә нидер пешә,
Әнкәем аш-су әзерләп
Көтәдер кебек, көтә.

Нинди рәхәт булган икән
Әнкәй исән чагында.
Хәзер беркем каршыламый
Мине капка алдында.

Суынды нигез, әнкәем,
Киткәчтен дөньялыктан,
Төшендем, нигез җылысын
Ул гына саклап тоткан.

Кояш нурлары да инде
Җылыталмый җанымны.
Сагыну сагышы белән
Каршылыйм һәр таңымны.

Сагынамын әткәемне,
Әнкәем белән бергә.

Тилмерәмен якыннарым
Сезне тик бер күрергә.

Төшләремә керсәгез дә
Күңелем була кайчак,
Киткәннәрем, үткәннәрем
Күңелемдәдер һәрчак...

КОЙМАК ПЕШЕРЕП, ЗУРЛАП

Буран сызгыра урамда,
Соңгы дулавы микән?
Яз килә, диеп, көенеп
Үксеп елавы микән?

Буран җиле белән өйгә
Килеп керде саф һава.
Дөрелдәп янган мичемдә
Чыжылдый майлы таба.

Кайнар чәй – шифалы дәва,
Кыш көнендә, салкында.
Тәмле була, бәрәкәтле,
Пешсә коймак ялкында.

Чәй эчәбез тәмләп-тәмләп,
Буранның көен тыңлап,
Озатабыз без ак кышны
Коймак пешереп, зурлап.

КЫШКЫ ЧИЯ

Күбәләкләп яуган ап-ак карлар
Килеп куна битем очларына.
Күзләремдә ай һәм йолдыз нуры,
Бөтереләм хисләр кочагында.

Әмма күрмим яуган карларны да,
Җитәкләшеп үткән парларны да,
Син бит миңа бүген «сөям», диден,
Кыш көнендә пешкән чиям, диден.

Күкрәгемә кысып җылытырмын,
Чиям, диден, сине өшетмәм.
Мондый иркә, назлы сүзләрне бит,
Мин бит тәүге тапкыр ишетәм.

Күбәләкләп яуган ап-ак карлар,
Килеп куна битем очларына.
Иреннәрдә баллы чия тәме,
Эрим кебек синең кочагында...

ГАЗИЗЛӘРДӘН ГАЗИЗ ӘНКӘЙЛӘР...

1938нче елны әткәем белән әнкәем өйләнешкәннәр. 1941нче елны, ниһаять, күптән көткән бәбиләре туарга торганда гына, бөтен совет халкын кайгыга салып, каһәрле Икенче бөтендөнья сугышы башланган. Әнкәем мине күтәреп, үз авылына кайтып киткән.

1941нче елның 14нче ноябрендә җомга иртәсендә мин дөньяга аваз салганмын. Ниндидер сәбәпләр белән әткәйне 1942нче елны гына сугышка җибәргәннәр. Сугышка киткәнче әткәем мине күреп киткән.

Бәләкәй баласы бар дип тормаганнар, эшкә кушканнар. Көне-төне эш. Эшкә яраган бар кеше, бер караңгыдан икенче караңгыга хәтле, эштә. Бишекне бәләкәй арбага салып, арба тартып, әнкәем үзе белән мине дә алып барган уракка. Бераз үсә төшкәч, мине яслегә илтә башлаганнар. Әз генә хәтеремдә калган, юрганга төреп күтәрә иде әнкәйнең сеңлесе. «Ботка булса да ашап торырмын, яслегә илтмәгез, дип, юл буе елый идең», – дип сөйли иде апа.

Шулай бер көнне аш эчеп утырабыз (безнең якта аш ашыйбыз түгел, аш эчәбез диләр). Умачлы аш инде, солы оныннан. Умачның кылчыгы кадала, мин шул умачларны йота алмагач, төкереп, әнкәй күрмәсен дип, артка ташлап утыра идем.

– Нигә ипи ашамыйсыз, кызым? – дип сорасалар, «Паталай ипи бирми», – дигәнмен.

Шулай бер көнне, ашап утырганда гына председатель килеп кергән һәм:

– Кызым, нигә ипи ашамыйсыз? – дип сорый икән бу миннән.

Ул абыйның кушаматы «Паталай» булганны мин каян

белим? Күрәсең, кемдер минем хакта председательгә җиткергән булгандыр инде, әзмени куштаннар... Ул да миңа шул сорауны юкка гына бирмәгәндер бит инде.

Ахырда әткәем:

– Нишләргә дә белмәдем, өскә эссе су сиптеләрмени. Бәхеткә каршы, син аңа күзләреңне тутырып карадың да бүтән бер сүз дә эндәшмәдең, – дип сөйли иде.

Сөйли иде, дигәннән... Минем үземнең дә бераз хәтеремдә калган ул. Интегә-интегә көн итә торгач, ниһаять, сугыш туктады, Аллаһыга шөкер. Ул чакта мин өч яшь ярымлык бала гына булсам да, бу шатлыклы көнне хәтерләмим ни өчендер. Бәлки, әнкәем башкалар кебек сөенеп йөрмәгәч, бу көннең тантаналы көн булуы сизелмәгәндер. Сөенерлекмени? Әткәем егерме алты яшендә генә, сугыш яланында, 1943нче елның гыйнварында, Орлов өлкәсендә ятып калган. Өйдәге җаносеткеч ятимлек, кытлык турында сөйлисе дә түгел. Сугыш бетсә дә, интегүләр, җәфа чигүләр бик озакка барды. Ашарга «чәп» итәрлек тә ризык, киярге кием юк. Бер ындыр бәрәңге ишле гаиләгә ярты елга көчкә җитә, аннан, көннәр буена ачка какланып, тозлы су эчеп йөрибез. Ерак бабай (әнкәйнең үги әтисе) исән-имин кайтты сугыштан. Аңа ул вакытта 55 яшь иде. Инәкәй (әнкәйнең әнисе), мин аны бәләкәйдән үк инәкәй дидем, әнкәй, әнкәйнең ике сеңлесе, мин – ишле генә булдык.

Шуннан инде әнкәем авылына, Этәйгә күчеп китәргә булдык.

Анда безнең кечкенә өебез бар иде. Әнкәй нәрсәләр күтәргәндер инде, әмма уналты чакрым атлыйсы юл. Миңа дүрт кенә яшь.

Көн кыздыра, шултиклем арыдым.

– Аякларым авырта, әз генә булса да утырып торыйк әле әнкәем, – дим.

– Буралыга хәзер җитәбез, аннан соң алты чакрым гына кала, түз инде, кызым, хәзер барып җитәбез, – ди.

Утырып ял иткәнбездер инде ул. Анда күчкәч, әнкәй ындыр тирәли ур казыды, мал ындырга кермәсен, дип. Киртә тотарлык рәт юк. Әнкәй ур казый, мин карап утырам. «И әнкәй, дөньяны шәп итеп күтәбез инде без», – дип әйтәм икән, аны үзем хәтерләмим.

Интегәсе чаклар алда булган икән әле. Мунча юк, сабын юк. Өскә ябынырга инәкәем суккан бер кат җәймә. Ашарга үләннән башка бернәрсә дә юк, кияргә кием юк. Бер ситса күлмәк, ул да ничә ямаулы. Үлән, тоз, су – шул иде ашаган бар ризыгыбыз.

Бәрәңге утырттык. Бәрәңге ашыйсы килә, нигәдер бәрәңге бик әкрен үскән сымак. Әнкәй, мин бик сорагач, бераз гына чокып алды, бәрәңге дип инде, борчактан чак зуррак булгандыр. Пешереп ашагач, әллә агуландык, ул косабыз, ул баш әйләнә. Күрше Зөләйха апаларның сыеры бар иде, ул безгә сөтме, катыкмы биргәч, әзрәк хәл кереп киткән кебек булды.

Җәй көне ач булсак та җиңелрәк иде. Көннәр җылы, аяклар да өшеми, йөгерәбез яланаяк. Кыш җитә башласа, кара кайгыга калабыз. Аякка кияргә юк, уйныйсы килә. Ике өй аша яшьтәшем Үсинә яши иде. Аның да бер кат күлмәктән башка бернәрсәсе юк кияргә. Кар өстеннән яланаяк йөгерәбез, йә мин аларга, йә ул безгә.

Аның әнисе дә, Нәсүха апа, әнкәй белән беравылдан иде. Шулай бер көнне әнкәй каядыр чыгып китте. Кояшлы салкын көн, кыш урталары булгандыр инде. Мин тышка чыккан идем. Керәм дисәм, ишек келәсе төшкән булган икән. Аяклар бозлана башлады. Йөгердем бер күршеләргә, икенчеләренә – әнкәй юк. Йөгердем өч өй аркылы Нәсүха

апаларга, ярый әле, әнкәй аларда иде. Мичләре ягылган иде. Әнкәй мич алдына күтәреп, аякларымны җылытты да, күтәреп алып кайтып китте.

Урман терәлеп тора, ягарга утын юк, җирдә яткан чыбыгына да тияргә ярамый. Әнкәй бер бәйләм чыбык җыеп алып кайтып килә икән, бригадир күреп, тартып алган.

Бер җәйне тирес суккан булдык, мин дә тапташкан булдым, имеш, әнкәйгә ярдәм итәм. Яр буена тезеп сала бардык кибәргә. Өч көн үткәч, әйләндереп салыйк дип барсак, тиресләребезне урлап ташып беткәннәр. Әнкәем белән утырып еладык-еладык та кайтып киттек.

Ул вакытта да оятсыз кешеләр юк түгел иде. Шуңа ике гаилә кыш көне берләшеп яши идек, өйне җылытырга җиңелрәк булыр, дип.

Әнкәй көндез эштә. Төнлә аны кәнсәгә исполнитель итеп, ягъни кеше куарга чыгаралар иде. Һәркем заем түләргә тиеш. Кешедә бер тиен акча юк, каян алып түләсен ул заемны. Әткәй сугышта үлгәнгә миңа кырык сум акча килә, ул безгә эләкми дә, бурычка сугалар.

Өскә киярге күлмәк тә калмады. Шулай бер көнне бушка кием өләшеп йөриләр, Америка ярдәм итеп җибәргән, диләр.

Әнкәй: «Минем кызыма да бирегез әле берәр күлмәк, аның да әтисе сугышта үлеп калды бит», – дип сорады. Әлеге дә баягы теге бригадир бирдерттермәскә тырыша, «икенче килгәндә бирербез» дип бытырдый. Аны тыңламадылар, бирделәр, өстәп, тагын бер бәйләгән башлык та эләкте. Инде аңа сөенүем, рәхмәтләр укуым!

Тегеләрнең һушы китте, нишләп шушы бәләкәй генә бала, шулай сөйли белә, шундый теләкләр тели белә, дип.

Яңгыр көне-төне ява, ашарга кирәк бит инде, киттем үлән җыярга. Бер кочак алабута җыеп, манма су булып чыланып кайттым. Төшке ашка дип, әнкәем дә кайтып керде.

Үләнне турарга гына утырган иде, сүгенә-сүгенә бригадир килеп керде. Әнкәйнең үлән тураган тактасын тартып алды да, атып торып бәрде, үләннәр идәнгә чәчелеп идән тулды. Әнкәйне эшкә куа инде. Мин ач көе елап утырып калдым, әнкәем ач килеш эшкә китте.

Заманы шундый иде, дияр кемдер. Мин явызлыкны заманга сылтамас идем. Явыз кеше ул заманда да явыз булды, бу заманда да явыз!

Беркөнне әнкәй туган авылы Исанбайга барып кайтмакчы булды. Инәкәйләр берәр нәрсә бирмәсләр микән, дип. Әнкәйнең Зәйтүнә исемле сеңлесе, сугыш вакытында чит авылга йөреп укып, ун класс бетергән. Ул вакытта ун класс укыган кешеләр бик белемле булып исәпләнә иде. Шуңа чәчү вакытында аны үлчәүче итеп куйганнар һәм дә эш хакына капчык ярым арыш биргәннәр. Әлбәттә, әнкәйгә дә өлеш тигән. Көнендә урап кайтты. Утыз ике чакрым ачлы-туклы кешегә бик ерак юл. Күршеләргә кереп, ярма ярып аш пешерде. Инде ул ашның тәмлелеге!

«Кайчан соң, әнкәй, ул ашны эчеп бетерәбез дә, кайчан эчеп бетерәбез?» – дип, әнкәйнең теңкәсенә тидем. Әнкәйнең тәмам ачуы килгәндер инде, башка берне кундырып та алды. «Ул ашны хәзер эчеп бетергәч, яңадан нәрсә эчәрбез соң, нигә сиңа хәзер эчеп бетерү кирәк» – ди. «Мин савытын ялар идем, ярмасын», – дим.

Яңадан кәҗәбез дә булды. Сөте бик күп түгел иде инде.

«Көтүче савып эчә», – дия иде әнкәй. Күрше апа сөтенмаен, иреннән яшереп, ашамасын дип, безнең базга төшереп куя иде, ире бер яшь кыз белән чуала, диләр иде. Мин ач булсам да, тими идем аның сөтенә, кеше әйберенә тияргә ярамаганны аңлый идем.

Җәй печән вакытында әнкәй мине үзе белән печән чапкан җиргә, болынга ияртеп бара иде, чөнки колхоз печәнчеләрне аш пешереп ашата. Ите булмаса да, умач ясап пешерәләр иде. Миңа да өлеш тия иде. Шулай беркөнне, яңгыр явып кына үткән, юлны аркылы чыгып барганда акчалар таптым. Саный белмим. Кызыл, яшелләрен күрше кызы шундук миннән сорап алып бетте. Ул миннән күпкә өлкән иде. Ике берәр сумлык кына калган. Әнкәй шулай диде.

Беркөнне шикәр кайткан дигән сүз чыкты. Теге ике берлекне тоттырып, әнкәй мине дә җибәрде лавкага. Барып керсәм, шикәр сатылып беткән, капчык төбендә оны гына калган. Шуны миңа үлчәп бирде. Яулык почмагына салдырдым да төйнәдем. Их, тәмләп карыйсы килә, тәмен беләсе килә шикәрнең.

Түзмәдем, яулыкны чишеп телемне генә тидереп караган булдым. Башым әйләнеп киткән кебек булды. Шушындый да татлы ризык була микәнни дөньяда, дип уйладым. Кайтып кергәч, әнкәй күрде дә аптырап калды, бигрәк әз, сатучы сине алдаган бит, диде.

Күлмәгем тагын тузды, алырга акча юк. Ходай җан биргәнгә юнь бирә ди. Шөкер, зурәтием (әткәемнең олы абзыйсы) күлмәклек ситса җибәргән. Аңа сөенүем. «Каян белгән зурәтием минем күлмәгем югын», – дим әнкәйгә.

Икенче җәйдә әткәемнең апасы ситсалар алып кайтты,

күлмәклек, куфәйкәлек. Аякка әнкәй чабата алды, оек-оекбаш бар иде микән, хәтерләмим.

Беркөнне, кесәсенә салып, бер уч арыш алып кайтты әнкәй. Мине бик нык кисәтеп куйды, кешегә сөйли күрмә дип. Капка төбенә чыгып утырганмын да, узган бер кешегә: «Әнкәй ашлык урлап алып кайтмады», – дип әйтәм икән. Ул вакытта бер уч ашлык өчен дә төрмәгә утырталар иде.

Әнкәй беркөн:

– Мин бүген базарга барып кайтам кызым, – диде.

Мине урам аша, зурәби дия идем, шуларга кертеп җибәрде. Йомшак кар ява. Өй алды ишегең кар күмгән. Ишек ачылмый. Зурбабай ишекне этеп көчкә чыкты да көртне көрәргә кереште. Күпме вакыт көрәгәндер, миңа бик озак тоелды, чөнки мин яланаяк, яланөс идем. Бер күлмәктән башка өстә бернәрсә дә юк иде. Үзе чыга алгач, мине кертеп җибәрсә булыр иде бит инде. Ул бик коры, кырыс кеше иде.

Әнкәй сөйли иде. «Ут янып чирләгән чакларың күп булды», – дия иде.

Инде, үсеп җиткәч, шәһәрдә яши башлагач, флюорография үткәч, кальцинатыгыз бар, кайчандыр үпкәгез шешкән булган, диделәр.

1947нче еллар иде микән, җәй көне әнкәемнең нык итеп үкчәсе шеште. Сызлавына һич чыдый алмый, елый, ә бригадир эшкә куа.

Беркөнне өй түбәсенә менеп качып калды. Авылда врач юк, районга барырга машина юк, ачлы-туклы кыш чыккан айлар, көне-төне эштә. Әнкәем ай ярым җәфалангач, шеш үзе тишелеп акты, шуннан әзрәк сызлавы басыла башлады. Ашарга юк, мин җыеп алып кайткан үлән генә.

Әнкәй арба тартып Идел буена юа җыярга китте. Исмаил авылына унике чакрым атларга кирәк. Баруы, ярый, юкка булмады, бер арыш капчыгы туп-тулы юа алып кайтты. Сөенәбез, чи көе дә ашыйбыз, пешереп тә. Күрше зурәбигә дә керттек.

Элек бит кыш – кыш төсле, ә җәйләр җәй төсле иде. Без бала-чага Базы буенда кояш кызынып, су кереп рәхәтләнә идек. Базы аръягында җиләклек. Менә шулар дәвалагандыр инде кышын туңып чыккан җаныбызны.

Бер җәйне әткәемнең энесе кайтып төште шәһәрдән. Ул әнкәемне бик ихтирам итә иде. Куфәйкә тектерде. Өстә куфәйкә бар-барын, аякка киярга юк. Чабата булгандыр да ул, киндерәләр урап, бәйләп торасым килмәгәндер.

Күрше яшьтәшем Үсинәләр дә ипи салганнар икән. Үсинә бик тыныч, оялчан гына, ә мин бик кыю идем. Үсинә миңа классташ. Ул мине һәрвакытта:

– Әйдә, минем белән утыр әле. Яныма утырсаң, мин сиңа ипи бирәм, – дип, юмалап янына утыртырга тырыша торган иде.

Мин инде тәккәберләнеп: «Юк, без үзебез дә ипи салдык, утырмыйм», – дигән булдым.

Ничә ел гел аның белән генә уйнагач ялыкканмындыр да. Уенчык та ялкыта бит. Алар бер анага дүрт бала иделәр, алар да ач үсте. Ипи аңа да бик кадерле булгандыр.

Элеккеләр исемә төшсә, йөрәгем әрни, әле дә, үзем язам, үзем елыйм. Укып йөргән булабыз. Шулай беркөнне җыр дәресе булды. Үзебезнең укытучы Исламов абый каядыр киткән, аның урынына яшь кенә кыз Фәния апа керде. «Кемнәр җырлый белә?» – диде. «Әйт әле, күбәләк» дигән җырны җырлады. Аннан соң мин кулымны күтәрдем. «Җырла, Виниса!» – диде.

Ал урыйлар, гөл урыйлар
Атларның муенына.
Син керсәң дә мин кермим
Ятларның куенына,

– дип җырладым.

Мин җырлап та беттем, Фәния апабыз көлә-көлә класстан чыгып та китте.

Өйгә кайткач: «Мин бүген дәрестә җырлаган идем, ялгыш җырладым бугай», – дидем әнкәйгә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемкәе Клара.
Яшәсен Совет власы
Көннән-көн алга бара,

– дип җырласам, дөресрәк булыр иде, әйеме әнкәй? – дидем.

Мин беренче классның беренче чиреген беткәч, без Исәнбайга күчеп кайттык. Ул да булса, әнкәй Свердловскига китәргә җыенган икән.

Исәнбайга кайткач беренче төнне үк төш күрәм, әнкәйне җиде елга төрмәгә утырталар икән, дип. Куркып, кычкырып елап уяндым. Җиде ел аерылып тордык та, мин җиде классны беткәнче.

Әнкәем инде елап шешенеп беткән, кемнең инде бердәнбер баласын ташлап китәсе килсен.

– Нигә елыйсың, кызым? – диде әнкәй.

– Сине җиде елга төрмәгә ябалар икән дип төш күрдем», – дидем.

– Еласаң еламасаң да китәргә кирәк, – диде.

Озакламый, елый-елый хушлаштык. Аннан ул кире

Этәйгә кайтты. Әткәйнең туганнарына ияреп Свердлауга киткән.

Инәкәем бик тыныч, сабыр акыллы кеше иде, мин аны да җаным кебек күрдем, бик яраттым. Әнкәем киту белән кызамык белән чирләдем.

Шултиклем дә каты авырдым, ничек үлми калганмындыр. Аякка кияргә чабатам да, оекбашым да бар иде. Күлмәгем генә тузды. Әнкәйнең сеңлесе, үз итәген сүтеп, миңа шуңардан күлмәк тегеп бирде.

Кыш көннәре салкын, ягарга юк. Агапа (әнкәйнең уртанчы сеңлесе) фермада сыер сава. Мин төнлә чана тартып саламга бара идем, салам урларга. Салам җылысы гына күпмегә җитә инде. Көн саен бара идем, салкын өйдә торып булмый бит инде.

Яз җиткәч, ындырны чокый башлыйбыз, черегән бәрәңге эзлибез, кәлҗәмә дия идек, ул шултиклем дә тәмле сымак иде.

Мәктәпкә киткәнче инәкәемә елгадан су ташып китә идем. Сәгать юк, ничәдә уянып торып басканмындыр, әмма беренче булып бәкене мин тишә идем балта белән чүкеп. Алабай дигән бәләкәй генә эт бар иде, кемнеке булгандыр, безгә ияләшеп, бездә яши иде. Шулай бер иртән суга дип төшсәм, Алабайның башы гына ята, бүре ашап киткән. Ярый әле, миңа очрамаган ул бүре.

Беренче май, яз бәйрәме, аеруча исемдә калган.

Демонстрациягә чыга идек, кызыл, байраклар күтәреп, шундый күңелле, бөтен урам буйлап, атлыйбыз, җырлыйбыз.

Иң зур шатлык шунысы – демонстрациядән соң безне ашаталар. Ипи, аш, чәй бирәләр иде.

Күрше малае Тимерҗан да олы мис күтәреп килгән булган. Әле ул укырга кермәгән иде. Мисен корсагына каплаган да, башын коймага терәгән, елый мескен бала, укымагач, аңа аш юк, бәлки, аңа игътибар да итмәгәннәрдер. Аны кызганып мин елыйм. Аның да әнисе юк, үлгән булган.

Шулай Исәнбайга ияләшеп киттем. Әнкәемне төпчек абзыкаем заводка эшкә керткән. Эшли башлаган, бик күп акча эшли акмаса да, тамагы ипигә туя башлаган.

«Эш авыр, акчаны бик аз түлиләр», – дип язган хаты да килде, 300 сум Сталин акчасы дигән. Бер класс белеме дә булмагач, нинди яхшы эш инде аңа.

Күпмедер вакыт үткәч әнкәйдән посылка алдык. Сөенүебезнең чиге булмады. Инде шултиклем дә матур, төсле ун метр ситса алган.

Апам кул эшенә бик оста иде. Шул ситсадан барыбызга да күлмәк текте. Әнкәем тагын-тагын посылкаларын җибәреп торды. Үзен бик сагына идем, посылка килсә дә, посылка әнкәй түгел бит инде. Ничек акчасын арттыргандыр, әз генә акчасын безгә дә бүлә иде.

Шултиклем дә сагындык, сагынуга чыдый алмыйча инәкәй белән икәүләп елыйбыз. Көтә-көтә җиде ел вакыт үтеп тә китте.

Ул вакытта хәзерге кебек телефон бар идемени! Хат аша аралаша идек инде.

Шулай бер көн, җәй уртасы урамда, комда, бала-чагалар уйнап утырабыз. Безгә таба берәү йөгерә, ул да булса, күрше Гайнесафәттәй икән.

«Фатымакай, сөенче, кызың кайта», – дип кычкыра. Мин инде нишләргә белмим. Каршысына йөгермәкче булам, атлый да алмыйм, бот төбенә генә зур чуан чыккан

иде. Башта әнкәйне йөгереп барып, күрше кызы Галия кочаклады.

– Нигә син башта Галияне кочакладың? – дип, мин үпкәләгән булдым.

Әнкәем башына зәңгәр бизәкле ефәк косынка бәйләгән, күлмәге дә ефәк, бик матур, яңа куфәйкә.

Һәммәбезгә дә бүләкләр, кучтәнәчкә шикәр, чәй алып кайткан.

Элек отпускылар уникe генә көн иде. Аның өч көне кайтырга, өч көне барырга. Хәзерге кебек тыз-быз машиналар чабып тормый иде. Башта поезд, аннан, пароход, аннан унсигез чакрым җәяү барасы.

Җәй көне каникул вакытында, әнкәй мине дә үзе белән алып китә иде. Бөтенләйгә алыр иде, яшәр урыны юк, үзе дә кеше өстендә генә тора. Бер бүлмәдә өч кеше яшиләр. Уку елы башланганда тагын авылга кайтып китәм.

Бишенче класска күчтем. Агапаны кияүгә биреп җибәрдек. Салам юлы ябылды. Яңа ел каникулы башланды. Ягарга салам юк, утын юк. Нишләргә? Өй эче суык, тыш белән бер. Ерак бабай бөркәнеп яткан. Аптырап, утынга барырга булдым.

Инәкәемне кызгандым, чирләсә нишләрмен? Балта алдым, җеп алдым, аркан алдым, киттем Моклыкулга. Анда вак куаклык үсә иде. Безнең авылда зур урман юк иде. Күпме күтәрә алдым, шултиклем күтәрдем, шулчаклы алып кайттым. Үзәкне өзәрлек салкын җил, колакка гына өрә, шуннан соң колагым бик озак сызлады. Тора-бара утынга бару мәҗбүригә әйләнде.

Ерак бабайны да өйрәттем бу һөнәргә. Беркөнне ерак бабай барса, икенче көнне мин барам. Алтынчы сыйныфта

укыган чак. Мәктәптән кайттым, ашадым да утынга барырга булдым.

Авылдан дүрт чакрым ераклыкта корыган нарат агачы булды микән, ерактан ук күренә иде, авылдан ук. Киттем шул төбәккә, балта алдым, зур чананы тарттым.

Юл юк, кыш ае, юлны көрт күмгән. Тукай әйтмешли, киттем туп-туры карап. Барып җиттем. Шултиклем дә биек агачны ничек кисеп аударганны хәтерләмим. Тураклап чанага төядем, кайтырга чыктым. Караңгы төшә башлады. Мин елга тавын төшеп менгәндә караңгы төшкән иде. Ерак бабай килеп ята каршыга, сукрана.

– Шушылай итеп утын төйиләрмени, бәреп катырырлык!.. – ди.

Аңа каршы сүз әйтергә ярамый иде. Инәкәй аңа:

– Бәләкәй генә бала утынга китте, каршы алырга да бармыйсың. Син утынга барсаң, ул сине гел каршы алырга бара, – ди.

Юк, мине, утынга бар дип, арттан куалаган кеше булмады.

Ул вакытта бүреләр бик күп иде, миңа алай бүре очрамады, Ходай үзе саклагандыр.

Ерак бабай – әткәйнең үги әтисе, димәк, мин дә үги бит инде. Агапа да аңа үги иде. Төпчек апа гына, аның бердәнбер үз кызы иде, ул да кияүдә, үз гаиләсе белән тора иде.

Мин җиденче сыйныфны бетәсе елны әнкәйгә тулай торактан урын бирделәр. Җиденче сыйныфны беткәч, ул мине үз кырына, бөтенләйгә шәһәргә алып китте. Минем инде авылымны, инәкәемне калдырып китәсем килмәде, елыйм.

Инәкәемне әнкәйдән дә ныграк ярата идем шул. Ул да: «Сине сагынуыма чыдый алмый төнлә уянып, ишек тупсасына утырып елый идем, – дия иде, – чак хыялыйга сабышмадым». Менә шулай икебез ике җирдә саргайдык.

Тулай торак бүлмәсе тулай торак инде. Алты караватъ, сигез кеше. Бер тавыш-гауга куптарган кеше юк, барыбыз да дус, тату яшәдек. Мин инде урысча юньләп сөйләшә белмим, укырга кирәк. Әнкәй мине урыс мәктәбенә, кабаттан җиденче класска бирде. Урысча дөрес әйтмәсәм, урыс балалары көләләр. Укытучылар да аптырыйлар икән, «Математика шундый авыр фән, чикләвек кебек чертләтә, ә сөйли белми», – диләр икән.

Шулай җиденчене, сигезенчене беттем. Аннан инде эшкә кермәкче булдым, кичке укуга күчтем.

Әнкәй җилкәсендә күпме утырырга була? Шулай көндез эшлим, кич эштән кайткач укырга йөгерәм.

«Уралобувь» дигән, аяк киеме тегә торган фабрикага тегүче булып урнаштым. Күрәсең, әйбәт эшләгәнмендер, ярты елда разрядымны да күтәрделәр.

Эш хакын да ару гына ала башладым. Әнкәем пилорамада эшли. Ирләр эшли торган эш булса да, бу эшне ул җиңелгә исәпли иде. «Килгән елларда бик авыр булды. Хәзер йорт төзи башласалар, котлованны экскаватор казый, ә без көрәк белән казый идек», – дия иде. Төшке ашка бер стакан газлы су, бер сайка биргәннәр. Ул тамак ялгау гына бит инде. Өч елдан әнкәемә ун квадрат метрлы бүлмә бирделәр. Аңа инде чиксез сөендек. Трамвай тукталышы да якын.

Элек йортлар күп төзелә иде. Тораклар бушлай бирелә иде. Завод тагын яңа йорт төзеде. Безнең коридорда да зур-зур бүлмәләр бушады. Әнкәйгә ияреп, мин дә бардым зуррак бүлмә сорарга. Ике көн үткәчме, әнкәй, тутыйкош тоткандай, очып кайтып керде эштән.

– «Хабировага 18 квадрат метрлы 36нчы номерлы бүлмә», дип, исемлек элгәннәр проходнойга, – ди.

Инде күрсәгез ничек шатлануыбызны. Телевизор да алдык, суыткыч та. Кешегә бәхетле булу өчен бик күп тә кирәкми. Эшлим, укыйм. Арый идем, әлбәттә. Иртән сәгать алтынчы яртыда торып эшкә китәм, эштән кайткач укырга китәм. Төнге сәгать берләрдә генә йокларга ята идем. Шулвакытта сәламәтлегем бик какшады.

Ирләре сугышта үлгән тол хатыннарга фатир бирергә дигән карар чыкты, диләр. Мин, әлбәттә, йоклап ятмадым. Әнкәй урысча бик оста сөйләшмәгәч, бар җиргә дә үзем йөрдем. Киттем военкоматка, райисполкомга, депутатка.

Фатир алырга чиратка бастык, аерым фатир фатир бит инде.

Унынчы классны тәмамладым, Аллаһыга шөкер. Аннан соң инде бер еллык бухгалтерлар курсын беттем. Тик бухгалтер булып эшләмәдем, ул эшкә күңелем ятмады, чөнки мин тумыштан тик утыра белмәгән кеше.

Акча бар, кибетләрдә әйбер очсыз, ипи унбиш тиен, пирожок биш тиен, конфетның килосы бер сум. Театр, концертларда билет хакы ике сум гына.

Шул чор тормышымны бәйрәм итеп кабул иттем мин. Дусларым күп, барысы да әйбәтләр. Элек тәмәке тартып, аракы эчеп йөргән кызлар юк иде, булса да миңгә бер булгандыр. Бераздан техникумга да кергән идем, бәхетсезлеккә каршы, башым бик нык сызлый башлады.

Табиблар:

– Уку белән хушлашырга туры килер, сиңа ярамый, башыңа көч килер, – диделәр.

Озак көттермәделәр, әнкәемә эшләгән җиреннән бер

бүлмәле фатир бирделәр. Әмма ул трамвай тукталышыннан шактый ерак иде, шуңа без аңа бик сөенмәдек тә. Фатир үзе бик яхшы иде, ошамаслык түгел.

1971нче елны әнкәй отпускыга кайтып китте. Без икебез дә инәкәйне бик сагына идек. Ел да отпускыны шунда үткәрә идек.

Әнкәем авылдан урап килде. Инәкәебез нык чирләгән, ни дисәң дә сиксән яшь, дөнья көтүе авыр карт кешегә.

«Мин инәкәй белән әткәйне карарга кайтып китәм», – диде әнкәй, пенсиягә чыгарга бер ел чамасы калгач. Ул авылга кайтып китте.

Инде озакламый фатирны алыштыру чарасын эзли башладым. Ул вакытларда торакны сату-алу мөмкин түгел, алыштырып кына була иде. Көч-хәл белән фатирны алыштырып, 1974нче елны Уфага кайттым. Хәзер инде авылга сагынган саен кайта башладым. Ә инде отпускы вакытында саноторийга яисә туристик путевкалар белән ял итәргә барырга мөмкинчелегем була башлады.

Уфага күчеп килгәч, «Гидравлика» заводына эшкә урнаштым. Әллә урын алыштыру килешмәде, гел генә авырый башладым. Температура югары гына булмаса, ул вакытта больничный бик биреп бармыйлар иде. Больницага барам, больничныйда берничә көн торалар да, тагын эшкә, ә эшләргә хәлем юк. Үз гомеремдә тазалыкка һич туймадым. Әнкәем полиартриттан җәфалана башлады. Инәкәем дә бик каты авырып китте, хәтерен җуя башлады. Мин кайткач мине дә танымый. Үзен генә өйдә калдырып та булмый иде. Ул гомергә начар ишетте, өстәвенә, күзе дә начар күрә иде.

Күп итеп күчтәнәчләр алып кайта идем, ул шуңа сабый

бала кебек сөенә иде. Аңа булса да, булмаса да, болар барысы да сиңа, инәкәй, дия идем. Ул да мине нык ярата иде. Мине үзе кызы итеп исәпли иде.

«Дүрт кызым бар, иң әйбәте син, бәбәем», – дия иде. Чире дүрт елга сузылды. Аны бәби караган кебек карадык. Беркем дә мәңгелек түгел шул, сиксән сигез яшькә җитеп, бакыйлыкка күчеп китте инәкәем.

Инде кайгыруым, елавым аның өчен. Кайгымны әзрәк таратыйм дип, отпускы алдым да Мәскәүгә китеп бардым. Юк, андый зур кайгыны Мәскәү генә басамыни инде.

Әле дә елый-елый язам шушы юлларны. Ел да, менә утыз ел була 22 июньдә ул үлгәнгә, гел хәер биреп, Коръән укытып торам, ул минем гел исемдә.

Инәкәй үлгәч, Ерак бабай:

– Инде ничек мин берүзем торырмын? – дип елый башлады.

Әнкәй, аны кызганып, үги булса да әткәй бит инде, жәл, тагын да авылда торып калды.

Ерак бабайны үз кызы да чакырган иде дә, анда бармады. Үз өендә тыныч кына яшәп өйрәнгән кешенең ишле гаиләдә торасы килмәгәндер инде.

Әнкәем ун ел буе Ерак бабайны карады. Ул үпкәсенә салкын тидереп, йөз яшькә җитәргә ничәдер ай калганда вафат булды. Врачка барырга риза булмаган. «Бармыйм!» – дип кырт кискән. Песиен бик ярата иде, шул песи тышка чыгып, озак кына кайтмаган, шуны эзләп йөреп, салкын тидергән үзенә. Ул алты яшендә ятим калган булган. Беренче бөтендөнья сугышында, 1914нче елны пленга эләккән, алты ел Германиядә яшәгән.

Аннан гражданнар сугышы, Икенче бөтендөнья сугышы,

бер рәхәт тә күрмәгән, туксан тугыз ел ничек яшәгәндер.

Аннан соң әнкәем бөтенләйгә минем янга Уфага күчеп килде. Шулай да җәйгелеккә күршеләрен, дусларын сагынып авылга кайтып йөри иде. Соңгы елларда инде аяклары хәлсезләнде, атлый да алмый башлады. Җәй көне үзем белән бакчага алып китә идем. Җәй буе шунда ятабыз. Урман кырда гына, саф һава. Ашарга азык бетсә генә, әнкәй янында кеше калдырып, Уфага кайтып килә идем.

Үземнең мунча юк, кеше мунчасына йөрибез. Әнкәйне арбага утыртып тартып алып бара идем. Бер шулай соң барырга туры килде, караңгы төште, әнкәйне алып кайттым, һич торгыза алмыйм гына, көчем җитми күтәрергә, көчкә күтәреп керттем.

Шигырьләр дә языштыра идем. Язам да әнкәйгә укыйм. Белеме булмаса да, күңеле белән тоя идеме, «Монысы бармый, ә монысы шигырь генә», – дип, минем шигырьләремә үз бәясен бирә иде. Шулай итеп, әнкәем минем тәүге редакторым да, тәнкыйтьчем дә булды. Хәтере бик яхшы булды аның. Мин бер әйтсәм, шундук отып та ала иде. Кайсы илнең башкаласын сорама, белә иде.

Радио тыңларга бик ярата иде. Нәрсә тыңлый, мин кайтып кергәч тә түкми-чәчми сөйләп бирә. Азак инде бөтенләй тора алмый башлады, тирәсенә мендәрләр куеп, сөяп утыртырга тырышып карыйм, авып китә иде. Бармаклары да кечерәеп бетте, кашык та тота алмый башлады. Дарулар да ала идем күп итеп, ярдәме тими иде нигәдер.

Элегрәк, йөри алганда, больницага да күп тапкырлар салып карадым. Соңрак тәрәте дә астында булды. Юештә

ятмасын дип, гел астын карап кына тордым. Шуннан инде ашавы да кысылды.

Инәкәйнең язмышы аны да урап үтмәде. Акылы да зәгыйфьләнде, ишетми дә, күрми дә башлады. «Синең инәң юкмыни соң ул?» – дип тә, миннән сорый иде. «Минем исемем ничек, син белмисеңме?» – дип сорый иде. Беркөнне иртән уянды да: «Бәбекәччәем, бәбекәччәем, мин үләм», – диде.

Шуннан соң ике көннән әнкәем дөнья белән хушлашты. Дүрт айдан сиксән сигез яше тулган булыр иде. 2005нче елның 14нче маенда мәңгелеккә күзен йомды. 1917нче елның 2нче октябрендә туган булган.

«Миңа рәшәткә алып булашма, үлсәм, әнә келәтне илт тә куй», – дия иде. «И әнкәччәем, нишләп мин келәтне илтеп куйыйм инде, мин сиңа рәшәткәнең иң әйбәтен алып куячакмын», – дидем.

Гомумән, тәм-том булса, башта аңарга ашатырга тырыша идем. Исән булып яшәсәм, җитешермен әле тәмтомны ашарга», – дип уйлый идем. Үзе бәләкәй генә булса да, буйсынганны ярата иде, бик таләпчән булды. «Миңа бит инде алтмыш яшь, һаман да мине өйрәтәсең», – дисәм. «Бәй, Виниса, сине кемдер воспитывать итәргә тиештер бит», – ди торган иде. Гел башым авырткангамы, хәтерем начарлана, тиз оныта башладым. Шуңа инде ул миңа: «Менә ул бестолковый башың белән ничек ун ел укыдың син?» – дип шелтәли иде.

Әнкәем әткәемә гомере буена тугры булып калды. Гел, кая барса да, мине гел үзе белән ияртеп йөртте.

Свердлаута барганда миңа ундүрт яшь кенә иде. Кунакка

барсак та гел бергә бара идек. Бер ят ирнең дә әнкәемә кулын салганын күргәнем булмады. Кешедән ким-хур түгел иде, акыллы да, тыйнак та иде. Чит кеше баламны кагар дип курыкты.

Мин аның сиксән яшенә шигырь юллары бүләк иттем:

Ялгыз көннәр, ялгыз төннәр,
Зарыгып үткән еллар...
Абындырса да екмаган
Алга әйдәгән юллар.

Шатлыгың да, борчуың да
Мин инде ул, мин – кызың,
Икәү бергә җитәкләшеп
Үтәбез гомер юлын.

Багышлагансың үзеңне
Миңа, җан җимешеңә.
Шундый гына бәхет синең
Тигәндер өлешеңә.

Дөнья булгач, төрле чаклар була, катырак бәрелгән вакытлар да булгандыр инде, алай үзем беренче башлап тиргәшә башламый идем. Ул, горурланып:

– Ә син миннән куркасың. Миннән курыксаң да, башка кешедән курыкма, – дия иде.

Хәзер инде ул киткәнгә ничә еллар үтте... Юксынам, сагынам, бәлки, бер ялгызым торып калгангадыр. Ел саен Коръән укытам, әле кулымнан килгәндә, дип. Каберен чистартам. Инәкәй белән Ерак бабайныкын да. Чәчәкләр салам ел да.

Әнкәем бик изге, ярдәмчел иде. Үзе таләпчән, кискенрәк кеше булса да, бәлагә дучар, мохтаҗ кешеләргә ярдәм кулын сузарга һәрчак әзер иде. Нык гадел булды, урлашканны, алдашканны яратмады. Әнкәемнең бер гөнаһы да юктыр, дип уйлыйм Ходай алдында.

Инде урыннары оҗмахның түреннән булсын, безнең өчен җан атып гомер кичергән газизләрдән газиз әнкәйләрнең.

ФАҖИГАЛЕ «АЛДАУ КӨНЕ»

Булган хәл

Аяк терәп ял итеп ята торган заман түгел, сугыштан кайтып кергәннең икенче көнендә үк Зариф районга юл тотты. Заманына күрә белеме дә ярап торырлык – җиде сыйныф. Укуның файдасы менә хәзер тиде – аны район милиция бүлегенә бик теләп эшкә алдылар.

Сугыштан соңгы елларда хәзерге кебек түгел, җинаять кылучылар бик аз иде. Җинаять дигәнең шул бер уч, бер кесә ашлык бөртеге алып кайтудан узмый. Әмма җәзасы хәтәр. Өйдә балаларың ашарга сорый димиләр, төрмәгә эләгүеңне көт тә тор.

Бу хәл Зарифның күңеленә ятып бетмәсә дә, ни кылсын, кайда булса да эшләргә кирәк. Аннан бу эш һәркемгә дә тәтеми, акчасы да кесәне тишми. Ниһаять, кигән формасы да үзенә күрә бер ыспайлык биреп тора иде егеткә.

Беркөн эшкә килеп кенә җиткән иде (күрше авылдан җәяү йөреп эшли), атылып-бәрелеп савучы Миңниса килеп кермәсенме! Пулеметтан аткандай сөйли башлады, сиптерә генә:

– Барыгыз хәзер үк Зәлифәгә! Каян алгандыр шешәсен, бер шешә сөт тутырып алып кайтып китте фермадан урлап, бөтен кеше дә урлый башласа, ни булыр! Себерәк, белсен әле, кеше ирен аздыру нәрсәгә китергәнен! Биш ел төрмәдә «ял итеп» кайтсын әле!

Егет эшнең нәрсәдә икәнен шундук аңлап алды: Миңнисаның уе – үч алу. Шикаятьчеләрне жене сөймәсә дә, бармый калу мөмкин түгел. Теш арасыннан гына сыгып рәхмәт әйтте әләкче хатынга, «хәзер барабыз» диеп калды.

Ярдәмчесе белән икәүләп Зәлифә торган йортка барып керделәр. Хуҗабикә коелып төште. Янәшәсендә кызы Зөлфия. Чибәрлеге! Аны күреп, егетләр икесе дә өнсез калды. Уналты-унҗиде яшьләрдәдер, дип уйлап алды Зариф.

Ниһаять, ул сүз башлады:

– Зәлифә апа, ни бит әле, сезнең фермадан сөт алып кайтканны күргәннәр (урлаганны дип әйтергә теле әйләнмәде), үзегез күрсәтәсезме, тентү ясаргамы?

Хуҗа хатын аңлап алды: Миңнисаның гына эше бу! Иртән эшкә килү белән үк ябышкан иде, «минем ирне аздырасың, себереләсең», диеп. Әйе, Муллаян Зәлифәгә яшь чагында гашыйк иде, тик кыз гына үзенә гомерлек яр итеп башканы сайлады. Ире фронтта үлеп калгач, Зәлифәнең йөрәгендә үзенә урын бар дип уйлый, ахры, Муллаян. Әмма хатын аны үзенә якын да китермәячәк.

Боларны Миңнисага аңлатырга ничек кенә тырышмасын, тегесе тыңларга да теләмәде. Әйе, бүген сөт алган иде шул, ире үлгәнгә ике ел иде, шул бер шешә сөтне Миңнеямал карчыкка сәдака итеп кертеп, иренең рухына догалар укытып чыккан иде. Ярамыйдыр да болай, әмма нәрсә бирсен, өйдә ләм-мим бернәрсә юк. Һәм моны милиционерларга сөйләп бирү дә мөмкин түгел.

– Юк, бернинди сөт тә алып кайтмадым, – диде Зәлифә.

Зөлфиясе гарьләнеп елап җибәрде.

Закон сакчылары нишләсеннәр, тентергә булдылар. Базга Зариф үзе төшеп китте, ярдәмче егетне төшерсәм, сөт табылса, котыла алмаячаклар болар, дип уйлады. Бәхеткә каршы, базда берни дә юк иде. Хезмәттәшен чакырып алып: «Син дә төшеп кара, шаһит бул», – диде. Чоланда да, кар базында да эзләгән нәрсә табылмады.

Миңнисаны чакыртып, ялган донос өчен шелтә бирмәкчеләр иде дә, Миңниса, котырган ерткыч кебек, үзе аларга ташланды:

– Мин үзем күрдем, карап тордым сөтне шешәгә тутырганын, нәрсә сөйлисез? Ә-ә, белдем, аның бит яшь кызы бар, шуңа күзегез төшкәндер әле! – Ләкин кычкырынудан, күркә кебек кабарынудан ары уза алмады.

Сөт вакыйгасының нәтиҗәсе шул – Зариф Зөлфиягә үлеп гашыйк булды. Ничек күрергә Зөлфияне, кайда очратырга дип баш ватмаган көне юк хәзер. Беркөнне әнисен очратып, хәлләрен сорашты.

– И Зариф энем, Миңниса көн күрсәтми бөтенләй, кичә сугышырга ук ябышты! – дип, хәсрәтен түкте тол хатын.

– Беләсеңме, Зәлифә апа, без иртәгәдән яңа бинага күчәбез, шунда җыештыручы кирәк булачак.

– И энем, мине фермадан кем җибәрсен!

– Анысын үз өстемә алам. Беркемгә бернәрсә сөйләнми тор! Кызыңа да тора-бара берәр эш табарбыз.

Чынлап та, бераздан Зөлфиягә дә эш булды, ул яслегә балалар карарга урнашты. Зариф, юк йомышны бар итеп, аның янына кергәләп йөри башлады. Яшь күңелгә күп кирәкмени – Зариф абыйсына үлеп гашыйк булды кыз. Чибәр, озын буйлы, төз гәүдәле, сәламәтлеге ташып торган егетне ничек яратмыйсың инде!

Көннәрдән беркөнне әнисе күрше авылдан апасының авыруы хакында хәбәр алып, тиз генә җыенып, шунда китте. Зөлфия эштән кайтып, йорт эшләре белән әвәрә килеп йөри. Капка шыгырдап ачылганга сискәнеп борылып караса – Зариф кереп килә.

Йөрәге, ярыннан ташкан елгадай, күкрәгеннән сикереп чыгарга әзер иде кызның. Җәй ае, бөтен халык аяк өсте,

илаһым, күршеләр күрсә? «Юк, курыкма, бер кеше дә күрмәде», – дип тынычландырырга ашыкты аны Зариф. Канаты ныгып җитмәгән кош баласына охшап калган Зөлфия егетнең куна калуына да каршы килә алмады. Аулак өйдә егетләр белән кызлар бергә куна инде, гомергә шулай килә.

Урынны үзенә сәкегә, Зарифка әнисенең караватына җәйде. Тик ничек түзеп ятсын егет? Нинди генә назлы сүзләр әйтелмәде икән бу кичтә? Сутышны урап кайткан егет шул ул, күпне белә, күпне күргән. Җырда әйтмешли:

Иркәләде, назлады,

Сылу күңелен яулады.

Иртән Зөлфия Зарифның йөзенә күтәрелеп карарга да оялды, күзләреннән яшь тамчылары тәгәрәде.

– И исәрем, ник елыйсың? – диде егет. – Мин бит сиңа башта ук әйттем, антлар иттем, һаман ышанмыйсың. Син минеке, мин синеке!

– Чынлапмы?

– Менә уборка беткәч, октябрь бәйрәменә гөрләтеп туй ясарбыз. Икебез дә эшләп торабыз, аңарчы акчабыз да булыр, Аллаһы боерса.

Кич әнисе кайтып кергәч, аңа күтәрелеп карарга да кыймады кыз. Зәлифә беркатлы яшүсмер түгел, барсын да аңлап алды. Иртәгәсенә Зариф исәнлек сорашкач, туры карамаска тырышып, идән юуыннан туктамыйча:

– Менә сезнеке ничек? Йә, сөйләп бир, нәрсә эшләттең минем җиләк кебек бердәнбер баламны – диде.

– Гыйшык уты бер кабынса сүнми бит ул, монысын гына аңлыйсыңдыр, Зәлифә апа. Икебезнең дә теләк белән булды.

– Син ничә яшькә олысың, соң ул сабый гына бит, сабый гына!

– Без көз көне өйләнешергә сүз куештык, мин Зөлфияне гомергә дә ташламаячакмын, – диде Зариф, юк-бар уйга урын калдырмаслык итеп.

Ана бераз тынычлана төште. Аннан соң Зариф – түрә кеше дә бит әле. Эштән куып чыгарса, кая барасың? Фермагамы? Юк инде, анда аяк та басмаячак башкача, сыер тизәгенә чумып йөрисе юк. Кызы да әйбәт урында. Каты бәрелеп булмый Зарифка.

Хәзер инде яшьләр, мөмкинчелек чыккан саен, очрашырга тырыштылар. «Зариф абый» түгел, «җаныем, иркәм» генә иде.

Егет беркөнне, эштән иртәрәк кайтып китте өенә. Кайтып керсә, әнисе белән бер чибәр генә ят туташ чәй эчеп утыралар. Улы кереп исәнләшеп өлгердеме, юкмы, әнисе теле-телгә йокмый китте тезеп:

– Менә, безнең авылга да врач җибәргәннәр районнан. Күрше Гөлчирә кортканың өен пункт иттеләр. Врач кызымның исеме Фазыйла була. Ул бездә торачак. Укыган, сугышта булган, орден-медальләр алып кайткан.

Зарифның бит мускуллары кабарып китте, ни әйтергә дә белмәде. Фазыйла анын ризасызлыгын сизмәде түгел.

– Юк, юк, мин медпунктта да тора алам, әнидән кайтып мендәр, савыт-саба гына алып киләм дә... – диде, кызарынып.

– Бездә генә торасың, уйлама да! – дип кырт кисте Зарига.

Фазыйла, эшкә барып киләм дип, чыгып китүгә, әнисе Зарифка ябышты.

– Син нәрсә, сөремең коелды? Шундый кыз! Үзе матур, үзе врач! Әллә доярка алмакчы буласыңмы?

– Бәлки, – диде Зариф, – әгәр миңа доярка ошаса!

– Өйгә кертәсем юк! Тирес исе иснәп яшәргәме? Кулыңа килеп кергән күгәрченне чыпчыкка алыштырмакчы буласыңмы? Үзең урында эшлисең! – дип өстәл сукты Зарига. – Надан калхузчы алмакчысыңмы? – Әллә бүрәнә аша бүре куды, әллә күңеле сизенде.

Әнисенә каршы эндәшеп өйрәнмәгән Зариф:

– Соң, әнкәем, гаиләбез ишле, апайлар бар, йокларга да урын юк бит... – дия алды.

– Бар! – диде Зарига. – Минем янда ятар, аннан, Ходай насыйп итсә, синең янга күчәр.

Фазыйла бик акыллы, уңган, төскә-башка да бик матур кыз иде. Зариф белән еш кына сөйләшеп утырыр булдылар. Күбрәк сугыштагы хәлләр турында сөйләшәләр. Берберсенә ияләшеп киткәннәрен сизми дә калдылар.

Зөлфия, сизенгәндәй, «син мине ташламассың бит, җаным?» дип, очрашкан саен кабатлар булды. Беркөнне исә Зариф эшкә килеп керү белән, Зәлифә егеткә тыныч кына сүз кушты:

– Безнең бәби булачак, син әти, мин нәнәй булачакмын, Аллаһы боерса...

Зариф ни әйтергә белми телсез калды. Ул үзе дә сизенгән иде инде. Һушын җыеп:

– Зәлифә апа, бу, әлбәттә, зур куаныч өчебез өчен дә, – дия алды. – Мин синең белән бу хакта үзем дә сөйләшмәкче идем.

– Нәрсә сузарга? – диде Зәлифә. – Аннан корсагы беленә башлар, кеше алдында оятка калырбыз, туйны хәзер ясыйк.

– Мин бүген үк өйләнергә әзер лә ул, – дип ык-мык килде егет, – әнинең ишетәсе дә, тыңлыйсы да килми бу хакта...

Ул арада Фазыйла район үзәгенә эшкә керде, Зариганы үз янына санитарка итеп алды. Хәзер Зарифның әнисенең

вакыты да күбрәк кала, йорт эшен иркенләп эшли ала. Сөенече эченә сыймады. Ничек итсә итте, улын үз дигәненә күндерде – 7нче ноябрьне дә көтеп тормадылар, Фазыйла белән Зарифның туен туйладылар.

Туйның икенче көнендә, иртән эшкә килгәч, Зариф Зәлифәне кабинетына чакырып алды.

– Зәлифә апакаем, гафу итегез, нәрсә эшлим, әни чарамны калдырмады, үзәгемә үтте. Тик мин баланы ташламаячакмын, үстерергә ярдәм итешәчәкмен. Гафу итегез, булдыра алсагыз, – диде, күзләрен аска төбәп.

Кызының аунап-тәгәрәп елаганнарын әйтмәде Зәлифә, бернигә карамастан һаман Зариф өчен өзгәләнүләрен дә сөйләп тормады. Сөйләп ни үзгәртәсең, аналы-кызлы үз язмышларына күнгәннәр иде инде.

Күп тә үтми, Фазыйлага да хәбәр килеп җитте. Зарифның башка берәүдән баласы булачагын ишетеп, хәйран калса да, терсәкне тешләп булмый иде шул. Зариганың гына исе китмәде: «Тапканнар – карасыннар, озак көттермәс, үзебезнеке туачак», – диде каты гына.

1нче апрель көне иде. Зариф, велосипедына утырып, эшкә китте. Фазыйланың кәефе юк, җаны тыныч түгел. Кан басымы да югары. Килене, көтмәгәндә, һуштан язып егылгач, кайнана нишләргә дә, ничек ярдәм итәргә дә белмәде. Фазыйла аңына килеп, күзләрен ачты. Эче борып-борып авырта. Фельдшер бит ул, барсын да аңлап алды.

– Әллә районга шылтыратабызмы, әни? – диде ул. – Зариф, бәлки, ат табып больницага илтер?

Кайнана авыл советына йөгерде. Бөтен авылга бер телефон шунда гына. Зариф бүлмәдән чыккан булган, барысын да йомышчы хатынга бәйнә-бәйнә аңлатып, сүзмә-сүз җиткерергә куштылар.

Әмма Зариф, хәбәрне ишеткәч, көлеп кенә җибәрде:

– Мине алдамакчы буласызмы? Әле өч ай бар әле Фазыйлага бәбиләргә. 1нче апрель бит бүген, алдау көне!

Шул мизгелдә тагын телефон тавыш бирде. Күрше авылда бер хатын ярты бидрә ашлык урлап тотылган. Зариф шундук велосипедына атланып, чәчәрдәй булып чыгып китте. Барып җитеп, колхоз идарәсенә килеп керсә, аңа аптырап карап тордылар-тордылар да, пырхылдап көлеп җибәрделәр. Хезмәттәше мутлашкан булып чыкты Зарифның.

Конторага кайтып керсә, тагын шылтыратканнар авылдан. Ул аһылдап кайтып кергәндә Фазыйла исән иде әле. Өлгерә алмады Зариф, авылны чыкканда Фазыйла аның кочагында җан бирде.

Ул еллардан соң бик күп сулар акты, күп гомерләр үтте. Зариф белән Зөлфиягә бергә калырга язган булгандыр инде – күңел яраларының сызлавы басыла төшкәч, чәчләрен чәчкә бәйләделәр. Улларын бергәләп үстерделәр.

Шулай да «1нче апрель» дигән сүзне башкача ишетәсе дә килмәде ирнең. Фазыйланың язмышында үзен дә гаепле саный, «Алдау көне»н дә гаепли, «каһәр суккан көн» дип кенә җибәрә иде.

Нишлисең, кеше бәхетенә кеше керми, Ходай биргән язмышны Ходай гына үзгәртә аладыр дип саныйм мин үзем.

ДӘВА ТАПТЫМ

И-и Ходаем, чирләргә язмасын икән ул. Врачлар кулына калырга язмасын, мәйтәм. Бүлнистә ятам, инде унбиш көн дәваланам, алга китү юк. Дарулар кыйммәт, ат хакы. Акчаңа барып сатып аласың да шунда дәваланасың. Аны чирләмәгән кеше генә белмидер. Арка авыртуга чыдар хәл юк. Йоклап та булмый, торып та булмый. Кыскасы, торсам яталмыйм, ятсам торалмыйм. Авыртуына да түзеп булмый. Төнлә дә йоклап булмый, җанга төшеп сызлый гына бит. Төнлә йокламагач, иртән торуга күзләр шешенә.

Иртән сәгать уннарда врач килеп керә. «Хәлегез ничек?» – дип сорамый, «О-о, хорошо выглядите...» – дигән була, зур зәңгәр күзләрен ялтыратып. Шулай дип, безнең авызны яба да куя. Борылып чыгып та китә. Бар, зарланып кара! Тыңлый, ди, ул сине. Урыс әйтмешли, «ход конем делает».

Бермәлне температурам күтәрелеп китте. Тән уттай яна. Җәһәннәмнең үзенә эләккәндәй хис итәм үземне. 39да 5не күрсәтә градусник. «Дежурный врачны чакырыгыз әле», – дим, чак телемне әйләндереп. Ярты сәгать тә үтмәде, килеп керде врач. «Мин нәрсә эшләтә алам инде сезне? – ди. – Бу – чират чире – грипп. Вакыты җиткәч, үзе бетә ул», – ди. Менә шулай.

«Юк, мин әйтәм, булмый болай яшәп. Үләсе килми бит әле. Им-томга күчәргә кала инде. Беркөнне кулыма бер китап эләкте. Күрше әби бирде. Чүплектән табып кергән. «Сидек ракны да дәвалый», дигән. Нинди чирдән генә кулланылмый икән сидек?! Укып чыктым мин моны. Менә, хикмәт, мәйтәм, кайда икән?! Аптекадан да ат хакына дару алып йөрмәскә, врачка да ялынмаска... Дару үзебездән чыга, шуны да белмибез икән...

Бермәлне башым сызлый башлады. Әй сызлый, әй сызлый. Туктамый гына бит. Күрше әбигә әйтәм: «Әби, бигрәк башым авырта, дару да эчеп карадым, файдасы да юк», – дим. Әби әйтә: «Бәй, теге «сидек ракны да дәвалый», дигән китабыңны укып кара әле», – ди.

Ашыга-ашыга тегене тагын актара башладым. Ниһаять, эзләп таптым. Ул болай икән. Бер атна буе иртәнге сидекне җыясың, әчетәсең. Җылы мунчага барасың, мамыкны лычма итеп манчып, башыңа ябасың. Мунча булмаса, сидекне кайнатасың да ике сәгать суыткач, мамыкны чылатасың да ябасың икән. Аннан җылы шәл белән урап куясың... Шулай иттем. Тик бер атна җыйганчы, авыртуы беткән иде инде. Алай да, авансом булсын, дип алдан дәвалап куйдым. Профилактика!

Беркөнне кинәт кенә әни егылып китте дә аягын сындырды. Чак күтәреп торгыздым да «Ашыгыч ярдәм» чакырдым. Алып китеп дә гипс салдылар да кайтарып та җибәрделәр. «Больницага салмыйбыз, аны монда караучы юк. Ул бик карт», – диделәр. Шулай инде, карт кеше беркемгә дә кирәкми. Чакырдым участок врачын. Ул әни ягына күз салып алды да: «Андый картлар, күп дигәндә, бер ай гына яшиләр. Бот төбеннән аягы сынган бит, – ди. – Әзерләнебрәк торыгыз». Анальгин, баралгин язды да чыгып та китте. Башкача эзе дә булмады.

Шуннан теге китап искә төште. «Сидек бәйләргә кирәк», дигән уй килеп керде башыма. Керештем әнине дәваларга. Көн дә мамыкны манам да иртәнге сидеккә, ябам сынган җиренә. Бу шәп даруны түкми дә башладык. Көн дә өч мәртәбә. Әни шул тиклем күнегеп китте моңа, мин онытта калсам инде, ул онытмый иде. Үләсе әни, шулай итеп, дүрт

ай дигәндә, аягына басып йөри дә башлады. Белмим, әллә сидекнең ярдәме тиде, әллә вакыт дәвалады?

Тагын килеп керде врачыбыз. Профилактик тикшерү белән. Әнинең басып торганын күрде дә телсез калды бу. Күзен биш тиен кебек киереп миңа пышылдый: «Кара әле, йөри... йөри, – дип кабатлый. – Мин бит аны мәңгелек дөньяга киткән, диеп уйлаган идем, – ди. – Минем практикада мондый хәл булганы юк иде. Синең әниең генә шулай аякка басты. Мондыйларның терелгәне юк иде әле. Син аны ничек дәваладың?» – ди, исе китеп. «Гади генә аның дәвасы, сидек бәйләдем, акча да түкмәдем даруга», – дим. «Рәхмәт киңәшең өчен, игелек күр! – ди. – Күрше йортта кичә бер карчыкның аягы сынган, барып әйтим әле, компресс ясасыннар», – ди. «Сидекләрен бер атна буе җыеп өч сәгать кайнатып япсалар, тизрәк төзәлер, әйтергә онытмагыз!» – дим. Ышанды! Әйдә, барып әйтсен, врач практикасында терелмәсә, сидек практикасында терелсен!

ӘТИ, ӨЙЛӘН, ДИ

Әти көн дә: «Өйлән инде, улым», – диеп, теңкәмә тия генә бит. Менә, бүген дә таң белән миемне черетә башлады.

– Улым, – дигән була бу миңа ипләп кенә, – иллегә җиттең, башыңда чәчең дә калмады, гаиләң юк, балаларың да юк... Пенсиягә чыгар вакытың җитә бит инде. Мин картайдым, дөнья көтүе дә җиңел түгел. Минем кулымнан эш китеп бара. Соң нәрсә уйлыйсың? – ди.

– Кемгә өйләним соң мин, әти, миңа пар, яр булырдай авылда кем бар?

– Бәрәк-бәрәк, әстәгъфирулла, нишләп булмасын? Авыл тулы тол хатыннар, – ди бу миңа.

Мин әйтәм:

– Соң, нишләп мин тол хатынга өйләним?! – дим. – Бер мәртәбә дә өйләнеп карамаган егет башым белән. Гәҗиткә игълан гына язмасаң...

– Кызны каян табасың син? – ди әти. – Язсаң да табалмассың, хәзерге заманда синең яшьтә кызлар каян булсын?! Менә дигән уңган, эшчән хатыннар авыл тулы, – ди. Әнә, түбән оч Хәлимә, үзе уңган, балалары да кырында түгел. Үзе бай, аннан да яхшы хатынның булуы да мөмкин түгел.

– Нәрсә-ә-ә? – мин әйтәм, ачуым килеп китте, – ул синең яшьтәшең түгелме соң? Син нәрсә?

– Алайса, түбән оч Фәүзия. Бигрәк тә акыллы, сабыр хатын инде, – ди әти, һаман сүзен бирмәскә маташа.

– Соң аның бит биш баласы бар. Өеңә килеп тулсалар, өстәлдәге бөтен тәм-томны сыпыртачаклар, үзеңнең авызыңа да тимәячәк.

– Алайса, арка урам Нәҗибә, – ди.

– Нәрсә-ә-ә? Ул бит тутырган тавык төсле... Үзе кызыл-сары... Җитмәсә, күзләре кылый. Берсе бер якка карый, икенчесе – икенче якка...

– Аның урынына ул бер дә кияүдә булмаган. Утары тулы мал, – ди, һаман сүз ярыштырып.

– Соң, әти, – дим, – аның бит кара эш халатыннан башка киеме дә юк.

– Алайса, теге югары очта торган Фәриха.

– Син нәрсә инде, әти?! Ул синнән дә картрак түгелме соң? Әллә башың эшләми башлады инде. Бер егерме ел элек үзең дә чуала иден түгелме соң аның белән. Әнинең тиргәшкәне әле дә хәтердә. «Фәриха белән себереләсең», – дип. Синнән калганны ничек мин алыйм? Әһә! – мин әйтәм, һөҗүмгә күчеп. – Син үзеңә җайлыйсыңдыр әле.

– И-и юнсез! – ди бу миңа. – Менә, карап үстер, ишетерсең әллә ни... Син буйдак каласың, дип кайгыруым.

– Ну, ярар, әти, әгәр Нәҗибә бер мәртәбә дә кияүдә булмаса, шул сүзең чын булса, карап карармын, – дим.

Өйләнергә булдым инде. Әти дөрес әйтә. Югыйсә, авылда кызлар калмады. Бар да шәһәргә китеп бетте. Ул санаганнар да үлеп-фәлән китсә, гомерлек буйдак калу куркынычы бар. Өйләнәм, җәмәгать! Юкка әйтмәгәндер әле элеккеләр: «Урау булса да, юл яхшы, сукыр булса да, кыз яхшы», – дип. Нәҗибәгә өйләнәм!

САТУЧЫ БУЛЫГЫЗ!

Иң почетлы һөнәр иясе, беләсезме, кем? Сатучы! Элек «застой» вакытында кесәдә акча бар иде, ләкин ашамлыклар, әйберләр юк иде. «Дефсит» иде, Райкин әйтмешли. Ирегетләр, умарта тирәсендә гөжләгән кортлар сымак, сатучы хатын-кызлар тирәсендә бөтереләләр иде. Бигрәк тә, егерме сум гына стипендия алып укыган студентлар. Йөри-йөри иләшеп тә китәләр иде. Өйләнеп тә алалар иде. Гомерлек беркеп тә калалар иде. Сатучы кызлар менә дигән егетнең күңелен яулап ала иде дә, гомер буе бәхетле булып яши. (Ә инде бәхетсез инженерлар, укытучылар икенче сортта иде). Инде гади эшче хатын-кыз, илле проценты дисәм, ялганчы булырмын, әмма күбесе ялгыз картая иде.

Ә хәзер... Хәзер кибет киштәләре сыгылып тора әйбердән, әмма кесәләр буш. Урыс әйтмешли, «финансы поют романсы». Тагын кем аягына барып егылалар? Кем кирәк? Әлеге дә баягы шул сатучылар инде. Аларда акча – бер букча. Алъяпкыч кесәсе тулы. Үзен эшләп туйдыра алмаган ирләр аптырап калмыйлар, төсе дә, буе да ярыйсы булса, берәр байбичәгә баралар да керәләр йортка. Һәм бәхетле булып яшиләр дә. Кыскасы, бишлегә укып йөрисе дә юк. Инженер булам, укытучы булам, дип тырышасы да юк. Өчлесе дә бик җиткән. Исәпләп-хисаплап торасы да, тапкырлау таблицасын ятлап интегәсе дә юк. Калькулятор чутлый.

Кызлар, тырышып, җәфа чигеп, белем алам, диеп интекмәгез дә. Сатучы булсагыз, тамагыгыз да тук булыр, ирсез дә яшәмәссез. Менә, минем бер сатучы ахирәтем бар.

«Мин инде өч иргә чыктым. Берсе үлеп җитми, икенчесен табам, – ди. – Ил бетмәсә, ир бетмәс», – ди. Икенче ахирәтем буфетта эшли. Дүртенче ир белән тора. Ничек кенә яхшы торалар әле. «Син булмасаң, авыр бу дөньяда, ничек яшәр идем мин?!» – ди икән. Үзегез нәтиҗә ясагыз инде, кызлар, һөнәр сайлаганда ялгышмагыз! Сатучы булыгыз!

ТОЗ СИБӘРГӘ КИРӘК

Йокыдан уянып сәгатькә карасам, йә Ходай, сәгать телләре төгәл ике турында. Йөрәгем «жу» итеп китте. Мин фермада мал караучы булып эшлим бит инде. Баш чатный, кичә шулхәтле күп эчелгән... Аракысы, сәмәе калмады... Кая инде баш төзәтеп тору, киендем дә чаптым фермага. «Эһ» дигәнче йөгереп барып та җиттем. Ни күзем белән күрим, улаклар буп-буш, саламы да калмаган, яланып беткән. Сыерлар ач, кычкыралар. Шул мизгелдә персидәтел дә килеп җитте. «Әхмәдулла, – ди бу миңа, усал карап, – син кайда йөрисең? Сыерларыңны ашатмыйсың, тәгам ризыклары юк. Бер бөртек саламнары да калмаган». Мин әйтәм: «Минем сыерлар әллә кайчан ашап туйдылар бит инде», – дим. – Мин бит тозны төеп, салам өстенә сибәм. Шуңа алар саламын ашап бетереп, улагын да ялап куялар. Аннан тагын шул тозлы саламны кычкырып сорап торалар»...

Шуннан соң китмәсенме персидәтел кабынып, тирги башлады башкаларны. «Әнә, Әхмәдулладан үрнәк алыгыз, кырыгызда яткан тозны алып салуы озакмыни? Бик кыен эшмени?» – ди. Тетә генә боларны. Мин торам астан гына елмаеп, «шөкер, үтеп китте», дип. Шулчакны бетле күзле, елак Гали, күзләрен челт-челт йомып, китмәсенме тезеп: «Син нәрсә, Фатыйх Мәхмүтович! Ул бит сине алдады, ул махмырдан яңа йокысыннан уянып килде». Инде мин күзләремне челт-челт йомып карап торам, персидәтел йодрыгын төйнәп миңа таба килә башлады. И-и-и, китте мине алып-биреп тиргәргә, тегеләй-болай, китте тузып. Күзгә фонарь куя, дип торам. «Тагын бер шулай кылансаң, эчеп йөрсәң, куам мин сине фермадан, – ди. – Аннан табып

кара эшне авыл җирендә, бу сиңа кала җире түгел», – ди, төкереген чәчеп. «Һу, мин сиңа күрсәтермен әле, бетле күз», – дим елак Галигә. Астан гына тегеңә йодрык күрсәтәм.

Кич эшне бетереп кайтыр вакыт та җитте. Кайтканда берәү дә буш кайтмый бит инде, бу сер түгел беркемгә дә. Ә минем уй үч алу бит инде теге елактан. Чанасын әкрен генә килеп карасам, бу бер капчык кибәк салып, өстен каплап куйган. Капчыгын алдым да түктем моның кибәген. «Алмый тор әле, мәйтәм, елак!» Аның урынына кисәк-кисәк тоз тутырып, өстенә чак кына кибәк өстәдем дә көчкә күтәреп чанасына салдым.

Икенче көнне елак Гали, күзләрен челт-челт йомып, йодрыкларын төйнәп, очып кунмасынмы миңа. Үзе минем ярты гәүдәм хәтле генә, күшеккән чебеш кебек бәндә, очып-очып сикерә өскә. Мин ни, урынымнан да кыймылдамыйм бит инде. Ул һаман да туктамый. Тегеңә бер селтәп йодрык белән тондырган идем, чанасына барып төшмәсенме... Куркуыннан аты торып чапмасынмы тау астына. Ярый әле Гали тәгәрәп төшеп кала алды. Чанасыннан төшмәсә, нәрсә булыр иде?! Билгесез! Үзем дә аның өчен шөрләдем... Үлсә, Аллаһ сакласын! Тегенең җиде баласы, мичкә хәтле юан хатыны миңа калыр иде... Тәүбә әйттем. Шул көннән алып эчми башладым. Елак белән дә (тфү, ялгыш әйттем) Гали белән дуслаштым. Эшкә соңга калсам, ул да әләкләми, мин дә кибәген түкмим. Ә улакка тозны сибәбез. Персидәтел әйткәнне көтеп тормыйбыз. Сыерлар да рәхмәтле, сөтләре дә тәмле. Тәмле икәнен үзем беләм. Хәзер мин сәмәй түгел, сөт кенә эчәм.



Свердловскида эшләгән чак.



Әнкәем Мәгъдәния Галим кызы.

Әлфия Афзалова (уңда) белән.

Заводта җыр конкурсында.

Эчтәлек

Җанга шифа шигърият

Җир шарының оҗмахыдыр. 3
Сандугачым, кун учыма. 4
Сөйгәннәр матур була. 5
Сайларга кирәк берне. 6
Син сайрыйсың. 7
Яшик әле сөелеп. 8
Мәхәббәтем табылды. 9
Бары берничә адым. 10
Офыкларга карап. 11
Урап үтте авылны. 12
Вакыт та төзәтәлмидер. 13
Туегыз белән. 14
Онытылмый үткәнәр. 15
Бер генә. 16
Туган көнгә. 17
Яшә әле. 18
Туймадыңмы, дөньялык?. 19
Өзелде гомерләре. 20
Кадерен бел. 22
Син булмасаң янымда. 23
Бәгырьне өзәр микән. 24
Карамыйча беләккә. 25
Янмыйча түзеп кара. 26
Түзәм инде беразга. 27
Онытмадык. 28
Каршылыйк бергә. 29
Очрады юлымда. 30

Җан дустыма. 31
Ялгыз хатын. 32
Күк капусы. 33
Кил янына бичараның. 34
Сөекле кызыкаем. 35
Үзәкләрем өзелә. 36
Гармун моңы. 38
Соң булса да. 39
Язлар килә. 40
Иң кулай кеше. 41
Аралап кына килә. 42
Әбекәй дисәгез дә. 43
Телисеңдер күрергә. 44
Үзе иҗат итәдер. 45
Сөю утында яна. 45
Сугыш ярасы. 47
Яшәгез сөеп-сөелеп. 48
Абыема. 49
Сокланыплар туя алмыйм. 50
Әйләндермә башымны. 51
Ялындырган буласың. 52
Картәтием. 53
Алыштырмыйм акчага. 54
Кирәк сөйгән йөрәк. 55
Яңа елга. 56
Безнең кала. 57
Сагынып сөйләргә калсын. 58
Кадерле кешем. 59
Салкын көздә әни туган. 60
Туган көндә. 61
Карт буйдаклар. 63

Искә төшә. 64
Чана шуганда. 65
Белгеч тумаган әле. 66
Сагыну. 67
Коймак пешереп, зурлап. 69
Кышкы чия. 70
Үткән көннәр, үткән еллар
Газизләрдән газиз әнкәйләр. 71
Фаҗигале «алдау көне». 92
Елмаеп-көлеп кенә
Дәва таптым. 100
Әти, өйлән, ди. 103
Сатучы булыгыз! 105
Тоз сибәргә кирәк. 107

Литературно-художественное издание

Фаттахова Виниса Шагизадиевна

САНДУГАЧЫМ, КУН УЧЫМА...

Стихи, рассказы, юморески

(на татарском языке)

Әдәби-нәфис басма

Фәттахова Виниса Шаһизадә кызы

САНДУГАЧЫМ, КУН УЧЫМА...

Шигырьләр, хикәяләр, юморескалар

Мөхәררирләре *Ф. Т. Харрасова, Д. Д. Сөләйманова*

Рәссамы *И. Я. Нигъмәтҗанов*

Техник мөхәררире *Н. Ә. Хәбибуллина*

Отпечатано в типографии ООО "Полиграфдизайн"

Подписано в печать 15.01.2015 г. Формат 60х84/16.

Гарнитура Palatino Linotype. Бумага офсетная. Тираж 500 экз. Заказ № 60

Каһәрле сугыш башлангач, 1941 елның салкын көзендә, 14 ноябрь көнне, Илеш районы, Этәй авылында туганмын. 1949 елда беренче сыйныфка укырга кердем. Бер чирек укыгач та, әнкәйнең туган авылы Исәнбайга күчеп кайттык. Шуннан соң әнкәем, мине нәнәемә калдырып, Свердловскига китте. «Торырга урын булгач, сине дә үземнең янга алырмын», – дип хушлашты. Бу аерылышу җиде елга сузылды.

Ниһаять, җиденче сыйныфны тәмамлагач, әнкәй мине Свердловски шәһәренә алып китте. Бу 1956 ел иде. Яшьлегемнең иң гүзәл чагы шушында үтте. 1971 елны әнкәй, пенсиягә чыккач, авылга, өлкән яшьтәге әнисе белән әтисен карарга кайтып китте. 1974 елны мин дә Уфага килдем. Пенсиягә чыкканчы 23 ел «Гидравлика» заводында эшләдем.

2004 елны – беренче, 2009 елны икенче китабым нәшер ителде. 2015 елда Башкортстан «Китап» нәшриятында «Кышыкы чия» шигъри һәм чәчмә әсәрләр җыентыгым басылып чыкты.

Минем сүзләргә иҗат ителгән җырларны туплап, компакт-диск чыгардым. «Татар җыры» конкурсының 2000, 2003 еллардагы лауреатымын, «Туган тел» телевизион каналының рәхмәт хатына (2003) ия булдым.

Гомерем булып, таза-сәламәт булсам, иҗатымны дәвам итәрмен, Аллаһ боерса.